Утыз яшенә җитеп килүче баламның сөйләменә рус теленнән туры тәрҗемә дә килеп кергәли. «Кибеткә ипи артыннан» («в магазин за хлебом» була инде мәгънәсе) кебегрәк сүзтезмәләр колакны ерта, ипләп кенә төзәткәләп барам. Мәгънә аермасын дә төшендерәм. Юл уңае күз алдыннан уза баручы урман, болын, кыр, басу, елга, үзән атамаларының кулланышы турында сөйләп каласым килә. Тауның түбәсе генә түгел, бите, итәге дә булганын, «урман авызы», «елга тамагы» кебек сүзтезмәләрне ул беренче мәртәбә ишеткән кебек. Чынлап та, шулайдыр шул. Кайда, кемнән ишетсен? Безнең буын: «Гөл бәйләме ятып калды Чияле тау итәгендә», – дип җырлап үсте, ә хәзер яшьләр тугайлар, аланнар турында шигырьләр укымый, җырлар тыңламый. Без, өлкәннәр, белән сөйләшү һәм аралашулары да кыска гына хәл белешүдән узмый.

Сүзебез төшенкерәк рухта очланды. «И, әни, бер ун елдан ул сөзәк ярлар, елга култыклары, басу түрләре бөтенләй онытылыр инде», – дип куйды улым. Миңа бик күңелсез булып китте. Әллә кемгә үпкәлисем килгән кебек. Без яшьләр белән татар телендә сөйләшәбез, дип үзүзебезне юатабыз. Ә сөйләмебезнең көннән-көн ярлылана баруы турында уйлап караганыбыз бармы соң? Кемгә үпкәли алабыз инде моның өчен?

Авылга кайтып, бераз торганнан соң, фикерем бераз үзгәрде. Тик кайсы якка уйларга, сөенергәме әллә көенергәме? Сеңелемнең өченче сыйныфка баручы кызы минем белән рус телендә сөйләшә башлагач, балаларыбыз, бик үк камил булмаса да, шөкер, ана телендә аралаша әле, дип үз-үземне юатырга мәҗбүр булдым. Ә менә алардан соң үсеп килүче буын туган телен бөтенләй санга сукмый булып чыга бит. Татар авылында үсә, ә эти-әнисенә, әби-бабасына русча эндәшә сеңелнең кызы. Миңа да. «Мин русча белмим шул», – дип әйтеп карыйм, колагына да элми. Курчаклары белән дә рус телендә «аңлаша». Ә курчак уены «Youtubers Life» формасында: я үзе, я курчагы блогер моның. «Кызыгыз минем белән чит телдә сөйләшә», – дип әнисенә әләкләп карадым. «И, апа, укытучысы өйдә татарча сөйләшмәскә куша бит», – ди гаепле кеше кебек акланырга тырышып.

Сөйләм байлыгы, чисталыгы турындагы уйлар артка күчте хәзер. Телнең исән калуы, яшәве өчен борчылыр вакыт җиткән икән бит инде.

Тик барыбер күңелне төшерәсе килми әле. Әнә өч яшьлек малайлары теттереп үзебезчә тәтелди. Шул балалар белән «Шаян ТВ»ны карап утырганда популяр мультфильмдагы Маша белән Аюның татарча сөйләшкәнен ишетеп тә азрак күңел булды. Бөтенләй өметсезлеккә бирелергә түгелдер, бәлки? Ничек уйлыйсыз?




# ИНГЛИЗ ТЕЛЕН ӨЙРӘТӘБЕЗ, Ә ТАТАР ТЕЛЕН?

*Мин рус кешесенә тормышка чыгасымны алдан ук белә идем, чөнки әтием рус милләтеннән, ә әнием – чип-чиста татар хатыны. Шулай булды да. Ике ир бала таптым. Олысы мәктәпкә йөри башлады.*

**Лилия СЕРЕБРЯКОВА**

Һәм менә улым өченче сыйныфка җиткәч, сорау туды: мин үз баламның татар телен өйрәнүен телимме? Уйга калдым. Мин, репетитор яллап, балама инглиз телен өйрәтәм, аны камил белергә тиеш, дип саныйм, һәм балалар инглизчәне, сөйләшә алырлык дәрәҗәдә булса да, өйрәнерләр, дип ышанам. Ә минем туган телем, аның белән нәрсә булыр? Әбием белән бабам, аларның мине ничек тәрбия итүләре исемә төште. Безнең тамырларыбыз – һәрбер күзәнәгебездә. Сүз дә юк, инглиз телен белү бүгенге заманда бик кирәк. Ләкин туган телебезне белү дә бик мөһим, чөнки ул – безнең балаларыбыздан калган, буыннан-буынга күчеп килүче мирас.

Ни өчен соң балага кечкенәдән үк инглиз телен өйрәтү өчен мөмкинлек табыла, без аларны өстәмә дәресләргә йөртәбез, репетиторлар яллыйбыз, ә үз туган телебезне кирәксезгә саныйбыз? Ләкин мин һәр кешенең канына милләт коды салынганына ышанам. Минем улларым да, татар телен өйрәнеп, үзләренең көчле нәсел һәм халык дәвамчылары булуларын төшенерләр, милли традицияләрне хөрмәт итәргә өйрәнерләр.

Телләрнең һәм халыкларның һәркайсы үзенчәлекле, уникаль. Ләкин үзеңнең кем булуыңны аңлау өчен тамырларыңны, традицияләрне, ана телеңне белү кирәк.

# “КЕШЕЛӘРНЕ ШАТЛАНДЫРЫРГА, ГАҖӘПЛӘНДЕРЕРГӘ, АЛАРГА ЕЛМАЮ БҮЛӘК ИТӘРГӘ, КҮҢЕЛЛӘРЕН КҮРЕРГӘ ЯРАТТЫ УЛ...”



***Милләттәшебез Әнвәр Сөнгатулла улы Гыйззәтуллинны Самар татарлары арасында күпләр белә торгандыр. Шәһәребезнең Җәмигъ мәчетен сала башлаган беренче көннәрдән үк ул - гыйбадәтханәне төзүгә, аннары күп еллар аның эшчәнлегенә зур өлеш кертеп яшәгән кеше. Әнвәр әфәнде мәчеттә ревизия комиссиясе әгъзасы иде, кизү торучы булып та эшләде ул. Гыйбадәтханә йортындагы искиткеч гөлбакча да – Әнвәр әфәнде һәм аның хатыны Мәрьям ханым куйган тырыш хезмәтнең күркәм нәтиҗәсе. “Матурлыкны яраткан кеше таш бакчаны да гөлбакча ясар”, - диләр бит. Әйе, чәчкәләрне рухи дөньясы бай булган, нечкә күңелле кеше генә үстерә ала. “Кулыннан гөлләр түгелә”, - дип тә уңган, булдыклы кешеләр турында гына әйтәләр бит.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**

Үз вакытында Әнвәр абый үзенең күңел җылысын биреп утырткан хуш исле чәчкәләр, куаклар, агачлар мәчеткә килгән һәр кешенең күңелен күтәреп җибәрә, соклану хисләре уята. Гөлбакчага хозурланып торганда, күпләр шушы гүзәллекне булдырган кешеләргә рәхмәт укый торганнардыр.

Әйе, гомеренең соңгы көннәренә кадәр мәчеткә юлын өзмәде Әнвәр абый.

84 яше туларга ун көн кала, 14нче августта, Әнвәр Гыйззәтуллин якты дөнья белән хушлашты...

Әнвәр абыйны искә алып, аның турында күп язарга була. Бай күңелле, миһербанлы, уңган, булдыклы кешенең хезмәт җимешләре дә, игелекле гамәлләре дә күп була бит ул.

Ә менә аның тормышын бизәгән тагын бер яраткан эше турында язып үтмичә мөмкин түгел. “Сәләтле кеше - һәрьяклап сәләтле”, - диләр бит. Әнвәр абый Самар татарларына фокус күрсәтүче буларак та таныш иде бит әле. 35 ел буена шәһәребезнең танылган “Ялкынлы яшьлек” ансамбле концертларын үзенең тылсымлы номерлары белән бизәп яшәгән кеше ул.

“Әнвәр әфәндегә мондый сәләт кайдан килгән булган икән?” – дип гаҗәпләнерләр, бәлки, күпләр. Татар сәнгате осталары арасында иллюзиячеләр еш очрамый бит!

Әнвәр абыйны иллюзия сәнгате кечкенәдән кызыксындырган. Ә армиядә хезмәт иткәндә аңа бу оригиналь жанр белән якыннан танышырга насыйп була. Эш шунда ки, аларның хәрби часте урнашкан Муром шәһәренә гастрольләр белән эстрада һәм кино артисты, фокусчы Арютун Акопян килә. Фокусларын күрсәтер өчен аңа ярдәмче кирәк була, һәм Әнвәр өч көн танылган иллюзияче белән бергә чыгыш ясый. Рәхмәт йөзеннән Акопян егеткә ике фокусының серен ачып бирә.

Инде хезмәтен тутырып кайткач, тора-бара Әнвәр әфәнде тамашачылар алдында чыгыш ясап, аларга үзе уйлап чыгарган фокусларны күрсәтә башлый. Башта ул авиация заводының үзешчән сәнгать хезмәтчәннәре коллективында Киров исемендәге Мәдәният Сараенда чыгыш ясый. Ә “Ялкынлы яшьлек” ансамбле оештырылгач, бире дә 35 ел буена татар тамашачысына тылсымлы номерларын бүләк итә.

Бөтен фокусларын Әнвәр әфәнде үзе уйлап чыгара торган булган. Иллюзияче эшендә математик төгәллек, зиһен үткенлеге, артистизм таләп ителә. Тамашачы “хәйләне” сизмичә, сәхнәдән күрсәтелгән күренешкә ышанып калырга тиеш.

Ә моның өчен кулларның җитез хәрәкәтләнүе, реквизитларның дөрес урнашуы кирәк. Әлбәттә



*Кечкенә Әнвәр әти-әнисе белән*



инде, Аллаһы Тәгаләдән бирелгән талант та мөһим роль уйный. Һәм инде гомер буе шушы сәләтне үстереп, камилләштереп, шомартып, яңалыклар кертеп, бертуктаусыз эзләнеп тору да сорала.

Әнвәр Гыйззәтуллин нәкъ шулай эшли дә. Кеше күңеленә могҗизага (ягъни яктылыкка, яхшыга) ышану салырга тырышып яши ул. Тамашачыларның фокусларны балаларча сөенеп, чын күңелдән гаҗәпләнеп карап утыруы, нарасыйларның, күзләрен зур ачып, чын могҗиза күргәндәй, аптырап калуы Әнвәр әфәндегә ләззәт китерә, тормышына ямь өсти.



*Әнвәр Гыйззәтуллин улы һәм оныклары белән*

“Бөтен фокусларның сере бер, ә аларны күрсәтү ысуллары төрле. Иң мөһиме - үз көчеңә ышану кирәк, шул вакытта тамашачы да сиңа ышаначак”, - дип әйтә торган булган Әнвәр абый.

Милләттәшебезне искә алып, аның якыннары, дуслары күңел түрләрендәге иң якты истәлекләре-хатирәләре белән уртаклаштылар.

Әнвәр әфәнденең улы - **Рәшит Гыйззәтуллин:**

“Әти кешеләргә елмаю, шатлык бүләк итәргә, аларны гаҗәпләндерергә ярата иде. Шуңа күрә фокуслар белән мавыгып киткәндер дә инде ул.

Һәр чыгышка бик тырышып әзерләнде. Өебез тулы кульъяулыклар, тартмалар, җепләр һәм башкалар, һәм башкалар булыр иде. Инде күп еллар тамашачылар алдында чыгыш ясамаса да, фокус уйлап табуын, реквизитлар ясавын барыбер дәвам итте ул.

Гаҗәпләндерергә ярата иде шул әти... Әниебез чирләгәч, мине дә бик гаҗәпләндерде ул. Ник дисәгез, кызурак холыклы әтиебезнең никадәр йомшак, назлы да булуын күрдем мин. Ул әнигә карата шундый ягымлы хисләр күрсәтеп, аны карап, тәрбияләп яшәде! Ашарына да үзе пешерде, башка эшләрне дә, бер генә дә уфтанмыйча, башкарды. Әни белән 60 ел бергә гомер иттеләр алар.

Гәрчә миңа карата да ул беркайчан да дорфалык күрсәтмәде, тавышын күтәрмәде. Барысын да яхшылап аңлатып бирер иде.

Әтидән үрнәк алырлык нәрсәләр күп булды. Мәсәлән, әтинең һәм аның энесе – Дамир абыйның үзара мөнәсәбәтләренә гел сокландым мин. Туганлык җепләре нык иде аларның. Дамир абый Мәскәүдә яшәсә дә, гел аралашып, күрешеп тордылар алар.

Бер-берсен кайгыртып, ярдәмләшеп, күңелләрен күреп, бер-берсенең кадерен белеп гомер иттеләр. Мин ике улыма да аларны үрнәк итеп куям. Сез дә үзара шундый дус булып, бер-берегезне якын итеп яшәгез, дип әйтеп киләм.

Нәрсәгә тотынса да, әти һәр эшне җиренә җиткереп эшләде. Заводта да, мәчеттә дә үз хезмәтен намус белән башкарды.

Әти белән мөнәсәбәтләребез яхшы булды безнең. Озаклап сөйләшеп утыра идек. Ә вафатына ике ай кала, ул миңа үзенең бәхетле кеше булуы турында белдерде.

Әтиемә әйтелмәгән сүзләр калды, дия алмыйм. Күп сөйләштек без. Әмма бер генә нәрсә – аның белән горурлануым турында үзенә әйтеп өлгерә алмадым шул...”

Әнвәр әфәнденең энесе - **Дамир Гыйззәтуллин:**

“Абыемнан мин ике яшькә кече. Ул мәктәпкә укырга кергәч, аның белән бергә мин дә белем алдым, дип әйтергә була. Аңардан карап, күп нәрсәгә өйрәндем. Беренче сыйныфка барганда, мин инде укый да, яза да белә идем.

Абый минем яклаучым да, саклаучым да булды. Балачагыбыздан алып, гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул миңа ярдәм итте. Бигрәк тә авыр чакларымда, тугыз ел элек хатыным вафат булгач, аеруча нык булышты ул, минем белән гел элемтәдә торды, тынычландырды, юатты.

Бер-беребездән читтә яшәсәк тә, без гел аралашып, күрешеп тордык. Мәнә әле язын абыем янында ике ай яшәп киткән идем. Төрледән-төрле темаларга озаклап сөйләшеп утырдык без.

Абый кызурак холыклы булса да, миһербанлы, мәрхәмәтле, гадел кеше иде.





*Әнвәр әфәнде хатыны һәм оныгы белән.*



*Гыйззәтуллиннарның дус гаиләсе.*

мәчете имамы **Габделәхат хәзрәт Мингачев:**

«Әнвәр әфәнде турында яхшы сүзләр генә әйтергә була. Мәчет бабайлары да аны мактап кына телгә алалар.

Туры әйтә торган, вәгъдәсендә торучан кеше иде ул. Бик эшчән, уңган, булдыклы, җаваплы. Мәчет бакчасын утыртып, аны яхшы итеп карап торды.

Мәхәббәтле иде Әнвәр әфәнде. Аллаһы Тәгаләгә ихлас күңелдән гыйбадәт кылды.

Урыны оҗмахта булсын, Раббыбыз Әнвәр Сөнгатулла улы Гыйззәтуллинның рухын шат кылсын”.

Үз вакытында “Ялкынлы яшьлек” ансамбленың алып баручысы булган **Исмәгыйль Мостафин:**

“Без Әнвәр абыйның улы Рәшит белән бер уку йортында – Самарның сәнгать академиясендә белем алдык. Ул балетмейстер һөнәрен үзләштерде, ә мин режиссерлык бүлегендә укыдым. Рәшит белән дуслашып киттек без.

Алар үз йортлары белән яшиләр иде. Мин үзләренә кунакка барып йөрдем. Әнвәр абыйның хәләл җефете - Мәрьям апа, бик уңган ханым, безне ачык йөз белән каршы алып, төрледән-төрле тәмле ризыклар белән сыйлар иде. Нинди күңелле чаклар!

Әнвәр әфәнде - лаеклы нәсел дәвамчысы. Аның әтисе - Сөнгатулла абзый, әнисе - Мәзлүмә апа бик дини кешеләр булганнар. Сөнгатулла абый – мәчет әһеле. Совет чорында да алар, качып-посып булса да, намаз укыганнар, корбан чалганнар. Мәзлүмә апа, унике яшеннән ятим калып, балалар

Үпкә саклый, үч тота белмәде ул. Кешеләр белән дә яхшы итеп аралаша иде.

Үз вакытында ул мине “Ялкынлы яшьлек” ансамблена да җәлеп итте бит әле.

Берникадәр вакыт аның белән бергә сәхнәдән фокуслар күрсәттек. Мин аның ярдәмчесе буларак катнаштым инде.

Абыем хатыны, улы Рәшит, ике оныгы, биш туруны (правнуки) өчен үлеп тора иде, үзләренә гел яхшы мөнәсәбәт күрсәтте.

Аның сабырлыгына, эчкерсезлегенә, намуслылыгына сокланып яшәдем.

Әнвәр абыемны бик яраттым мин. Аның үлеме безнең өчен кötелмәгән хәл булды. Әле яшәр кебек иде...

Урыны оҗмах түрләрендә булсын”.

Самар Җәмигъ





*Әнвәр әфәнде (сулда) һәм Рәшит Кәримов*



*Әнвәр Гыйззәтуллин хатыны, илене, туруны белән*

йортында тәрбияләнгән. Төрле авырлыкларга карамастан, ул анда да намазын калдырмаган.

Динебез Исламга ихтирам, мәхәббәт Әнвәр абыйга балачактан, әти-әнисеннән канына сеңеп калган булса кирәк. Ул да бит, Самар Җәмигъ мәчете әһеле буларак, күп еллар дин юлында хезмәт иткән кеше.



*Әнвәр һәм Мәрьям Гыйззәтуллиннар*

“Ялкынлы яшьлек” ансамблендә да Әнвәр абый Гыйззәтуллин белән туганнарча аралашып эшләдек без. Ул фокус күрсәтү серләренә үзлегеннән өйрәнсә дә, бу эшне һөнәрмәндләр дәрәҗәсендә башкарды. Тамашачыларны үзенә җәлеп итеп, хәйран калдыра иде. Һәр чыгышын кызыклы, күңелле итеп әзерләргә көч куйды. Ул бит оригиналь жанр белән шөгыльләнде. Ә татар сәхнәсендә – бу бик сирәк күренеш. Моны ул бик яратып, тырышып башкарды.

Әнвәр абый - энтузиаст, шәфкатьле, хәйләсез, ихлас күңелле кеше иде. Аның туганнары да шундыйлар. Әгәр гастрольләр белән, әйтик, Әбдери авылына барабыз икән, Әнвәр әфәнденең анда яшәүче туганнары безне кунак итмичә калмыйлар иде.

Малаена, оныкларына яхшы тәрбия бирде ул. Аларны үз үрнәгендә үстерде. Дин юлында булулары да Әнвәр әфәнденең тәрбиясеннән килә, дип уйлыйм.

Мин Әнвәр әфәндегә бик рәхмәтле. Ул миңа гел ярдәм кулын сузды, тормыш тәҗрибәсе белән уртаклашты, аталарча мөнәсәбәт күрсәтте. Әнвәр абый кешеләрне шатландырырга яратты. Тәрбияле, тәртипле кеше, лаеклы шәхес иде ул”.

Самар Җәмигъ мәчете коменданты **Рәшит Кәримов:**

“Әнвәр әфәнде мәчет төзелешендә беренче көннәрдән үк катнашып, күп еллар дин юлында хезмәт куеп яшәде.

Олылар белән дә, яшьләр белән дә уртак тел таба белде. Гыйбадәтханәдә кизү торганда да кешеләргә ачык йөз күрсәтте, авыр сүз әйтмәде. Сабыр кеше иде ул.

Әнвәр әфәнде миңа акыллы киңәшләре белән һәрвакыт ярдәм итте. Без бик дус идек. Аралашып яшәдек. Яхшы кеше иде ул. Аллаһы Тәгалә аның рухына кылган догаларыбызны кабул итсен”.





# “АНЫҢ КИҢ КҮҢЕЛЕНӘ БӨТЕН ДӨНЬЯ СЫЙГАН, ДИЯРСЕҢ...”

***Камышлы районының Рус Байтуганы авылында гомер итүче Минсәхи кызы Нурания Абзалованы инде бик күп еллар белсәм дә, мин бу ханымга һаман да сокланып туя алмыйм. Гомумән, аңа көн саен сокланырга мөмкин. Аның белән аралашкан саен үзенә карата гаҗәпләнү, хөрмәт хисләре туа тора.***

***Нурания апаның киң күңеленә бөтен дөнья сыйган, диярсең. Үз милләтенең язмышын тормышының һәр мизгелендә кайгыртып, башкаларның күңелен күреп, ярдәм кулын сузып, юмартлык күрсәтеп яшәүче шәхес ул.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**

Бер кешедә шулкадәр күңел байлыгы булсын да, шундый олы йөрәк типсен әле – исләрең китәр! Бер яктан Нурания апа йомшак, нечкә күңелле, хискә бирелүчән ханым булса, икенче яктан ул – үткен, максатына ирешүчән, чая кеше. Әгәр шушы капма-каршы сыйфатларга ия булмаса, ул тормышында шушындый зур уңышларга ирешә дә алмас иде, мөгаен.

Шунысы да игътибарга лаек – рус мәктәбендә белем алып, укыганда “Әлифба” китабын кулына да тотып карамаган Нурания апа татар телен камил белә, ана телендә матур мәкаләләр яза. Ә аның татар сөйләмен ишетсәгез сез! Аһәңле, тәмле итеп сөйләшә ул.

Гомумән, Аллаһы Тәгалә Нурания апаны үзенчәлекле, башкалардан аерылып торучы, аерым сәләтләргә ия булган шәхес итеп яралткан. Гәрчә язмамны укыганда, сез үзегез дә моңа инанырсыз.

### “БЕЗ МӘКТӘПТӘ РӘХӘТЛӘНЕП ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘ АЛМАДЫК”

**“Нурания апа, балачагыгызга кайтып килик әле”,** – дигән соравымны әңгәмәдәшем шатланып кабул итте.

“Ии, Миләүшә, без барыбыз да – балачактан, дигән гыйбарә яши бит. Бу – хак сүзләр. Кечкенә чакларым бер дә күз алдыннан китми минем. Хатирәләремне оныкларыма да сөйләп торам. Мин Камышлыда туганмын. Биш яшь тулгач, әти-әнием туган авыллары – Татар Байтуганына кайтып урнаштылар. Камышлыда алар йорт салганнар иде, әти ат караучы булып эшләде, әнием райисполкомда идән юып йөрде. Шушы өйне Татар Байтуганының Бигәш тавы итәгенә күчерделәр. Ничә ел шунда яшәгәч, өйне су баса башлады һәм аны мәчет янына тагын күчерделәр.

Авылда татар мәктәбе бар иде. Без килгән елны ул ябылды. Миңа рус мәктәбенә укырга керергә туры килде. Ике көннән соң өйгә кайттым да: “Бүтән мин мәктәпкә бармыйм!” – дип елыйм. Русча бер сүз белмим бит, укытучы сөйләгәнне дә аңламыйм. Шунда әнием миңа бик тә акыллы сүзләр әйткән иде: “Белем – үзең өчен юлдаш, дустың өчен – хәзинә, дошманың өчен – корал”. Ул вакытта моның мәгънәсенә төшенеп бетмәсәм дә, әниемнең күз карашыннан белем алырга кирәклеген яхшы аңладым. Ул үзе бер көн дә укымаган һәм гыйлем алуның никадәр мөһим булуын бик яхшы белгән, күрәсең.

Гомумән, әти-әниемнең тәрбиясен бәяләп бетергесез, аларның үгет-нәсыйхәтләрен күңелемә сеңдереп, гомер буе үтәп яшим мин. Ата-анам бик дини кешеләр иде. Апаларым Гөлсинәгә, Гөлфиягә, миңа кечкенәдән догалар өйрәттеләр, Ислам диненә зур хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләделәр.

Балачак елларыбыз авыр вакытка туры килде. Динне бетерделәр, ә мәктәптә татарча бер сүз әйтергә ярамый иде. Рәхәтләнеп ана телендә сөйләшмә әле! Бу хәлләр, әлбәттә, җанны телгәләде. Хәзер, шөкер, иреклек. Шуңа күрә яшьләребезгә киңәш йөзеннән шуны әйтәсем килә – туган телегезне өйрәнегез, аңарда курыкмыйча, рәхәтләнеп сөйләшегез. Бу – бит зур бәхет.

Мәктәптә татар телен үзләштермәсәк тә, әти-әниебез безгә аны бик яхшы өйрәттеләр. Мин аларга бик рәхмәтле. Артык акча булмаса да, “Пионерская правда”, “Сельская жизнь” гәҗитләрен, “Азат хатын” журналын гел яздырып алдык. Әни бәлеш сала да күршеләрне сыйларга чакыра. Әти барыбызга да тәрбия темасына кагылышлы яз-






*Фәргат һәм Нурания Абзаловлар*

маларны кычкырып укый – кыз кеше нинди булырга тиеш, хатынга, киленгә үз-үзләрен ничек тотарга. Аннары әни: “Йә, аңладыгызмы!” – дип мөһер сугып куя. Әни безгә гел шуны әйтеп килде: “Кызым, дошманыңа ачуың килсә дә, аңа начарлык теләмә. Раббым, Үзең хөкем ит, дип әйт”. Нинди дөрес сүзләр бит бу!

Байтуганга күчеп килгәч, әтием мал дәвалаучы табибның ярдәмчесе булып эшләде. Әни бит инде колхоз эшендә кайнады. Әти атларны аеруча нык ярата иде. Бу миңа да күчкән. Безнең йорт кешедән өзелмәде. Авыл халкы әтигә малларын карарга китерә иде.

Әтиебез – сугыш ветераны. Фронтта яраланган аягы гомере буе сызлап, үзен интектерде. Әни сугыш вакытында звено җитәкчесе булган. Тырышлыгы, уңганлыгы, эшчәнлеге өчен үзенә “чаткы” исеме биргәннәр. “Бөек Ватан сугышы елларында тылда күрсәткән фидакарь хезмәте өчен” медале белән бүләкләнде ул. Ашлык сукканнар алар. Әни шул вакытларны гел искә ала иде. Йөрәгенә шулхәтле үткән булгандыр инде. Ачялангач. Авыр эш.

Ульяновский өлкәсенең Кузоватов районында окоп казыган өчен үзләренә өчәр килограмм он биргәннәр. Әни шуңардан коймак пешергән. “Андый тәмле коймакны башка гомеремдә дә ашаганым булмады”, – дия торган иде. Ач булганга, ул коймак бигрәк тә тәмле булып тоелгандыр инде.

Әниебез әтине хөрмәт итеп, зурлап, ир итә белеп яшәде. Атабызның баш булуын күрсәтеп тәрбияләде ул безне. Берәр нинди карар кылырга булса, әтиегез ни әйтер, дия торган иде. Әтидән башка табынга утырмадык без, ашны да, иң беренче, аңа бирә иде әни. Һәм без дә нәкъ шулай ук. Гаиләдә ата кешенең абруе зур булырга тиеш, дип саныйм мин.

Әтиебез 1998 елда, 72 яшендә, вафат булды. Әниебез 2005 елда, 82 яшендә, үлде. Әни: “Бу дөнья белән алмагачлар чәчәк атканда хушлашсам иде”, – дип теләп утыра иде. Мин аңа: “Кем инде алмагачлар чәчәк атканда китә”, – дим. Аның сүзләре Аллаһы Тәгаләнең “Амин” дигән вакытына туры килгән, күрәсең, 20 майда, алмагачлар шау чәчәктә утырганда, якты дөньядан китте ул. Кышын, салкында кабер казучыларны җәфаламас өчен шулай теләгән булгандыр инде.

Мин әти-әниемә үз гомеремә сокланып яшим. Алардагы кешелеклелек, гаделлек, дөреслек, тормыштан ямь таба белү, туганлык хисләрен саклау! Шулкадәр авырлыклар аша үтеп, шушы сыйфатларның берсен дә югалтмаганнар бит!” – дип балачак хатирәләрен яңартты Нурания ханым.

**“Студент чакларыгызны да шулай яхшы хәтерлисезме?”** – дип сорыйм үзеннән.

“Студент еллары – аерым бер күңелле чак бит инде ул. Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, Шенталы медицина училищесына укырга кердем. Әни мине озата барды. Тантаналы линейкада укытучыларга карап торды да: “Бу кешеләрнең күзләре бигрәк





*Нурания Абзалова оныгы Альбина белән*










нурлы, кызым", – диде. Бер атна укыгач, өйгә шатлыклы хәбәр белән кайттым. Әнине кочакладым да: "Укытучыларның күзләре нурлы, дигән идең. Татарлар икән бит алар!" – дим. Ул укытучыларым белән хәзер дә аралашам мин.

Эх, нинди мөгаллимнәр укытты бит безне! Хирургия буенча дәресләр алып барган Әнвәр Салманович Суфьянов кына ни тора! Аның яхшылыгы, аның һөнәрилеге, гыйлемлелеге. Андый укытучылар күбрәк булса иде. Шундый төпле белем бирәләр ки, студент эскәмиясеннән яхшы белгечләр чыгаралар алар.

Әнвәр абый Суфьяновның лекцияләрен һич онытасым юк. Инде укып бетереп, эшли башлагач та, миңа еракта Әнвәр әфәнденең акыллы күзләре карап тора сыман иде.

Әнвәр абый белән бәйле бер кызыклы хәлне дә искә аласым килә. Без ирем Фәргат белән алтынчы сыйныфтан ук дуслашып йөрдек. Мин училищеда укыганда үзен армиягә алдылар. Аны озатырга бардым һәм Әнвәр Салмановичның дәресенә керә алмыйча калдым.

Әле дә хәтерлим – ул көнне "Столбняк и его профилактика" дигән теманы үзләштергәннәр. Әнвәр абый миннән: "Нигә дәрестә юк идең?" – дип сорады. Мин: "Егетемне армиягә озаттым", – дим.

Аның: "Егет ул ир түгел әле. Егетне озату – ул бер нәрсә, моны барысы да булдыра. Аны көтеп алу кирәк", – дигән җавабын хәзер елмаеп искә алсам да, ул чакта бер дә кызык булмады шул миңа. Шушы тема буенча җавап бирер өчен сигез тапкыр бардым мин Әнвәр абый янына!

Сигезенче мәртәбә килгәч: "Әгәр сез бүген дә миңа билге куймасагыз, биредә куна калам, китмим!" – дидем.

Әнвәр әфәнде белән бүген дә аралашып яшибез.

Фаинә Нәгыймовна Хәбибова, Әнвәр Сөләйманович Әхмәтшин да бик көчле укытучылар иде", – дип исенә төшерде күңелле студент чакларын Нурания апа.

**"БЕР РӘХМӘТ МЕҢ БӘЛАДӘН КОТКАРЫР"**

Нурания Абзалова 41 ел буена фельдшер булып эшләп, бер ел элек лаеклы ялга чыккан. Медицина белгечлеген сайлап алуы да очраклы түгел аның. Моңа кешеләргә ярдәм итү теләге этәргән аны.

"Кечкенә чагымда кем генә булырга хыялланмадым мин – агроном, зоотехник, укытучы... Бертуган апам Гөлфия медицина училищесында укыганда авылга кайта да безгә, фәләнфәлән кеше шундый хәлдә иде, табиблар аңа ярдәм итеп, үлемнән коткарып калдылар, дип сөйли.

Ә мин үз-үземә: "Кара әле, нинди кирәкле, әһәмиятле һөнәр икән бит бу!" – дип, апам кебек, медицина хезмәткәре булырга карар кылдым", – ди бу турыда Нурания апа.

Һәм аңа үз гомерендә күпләрне шулай ук үлемнән коткарып калырга туры килә, чөнки кешегә беренче медицина ярдәмен күрсәтү, чыннан да, бик тә мөһим нәрсә бит ул.

Укуын тәмамлагач, аны юллама буенча Бозбаш авылына эшкә җибәрәләр. Шул ук елда ул армиядән көтеп алган егете Фәргаткә кияүгә чыга. Татар Байтуганында каенана-каенатасы белән яшәп, Бозбашка эшкә йөри.

"Мин беренче киленнәре идем. Фәргатнең әти-әнисе мине үз кызларыдай кабул иттеләр, ике энесе дә гомер буе "апа, апа", дип кенә тордылар. Миңа да алар үз әти-әниемдәй булдылар. Бик яхшы кешеләр иде. Аллаһыга шөкер, дус яшәдек без", – дип җылы сүзләр белән искә ала каенатасы белән каенанасын Нурания апа.

Аннары яшь гаиләгә башта Татар, аннары Рус Байтуганыннан өй бирәләр.

Нурания ханымның апасы Гөлфия – Татар Байтуганы, ә үзе Рус һәм Чуваш Байтуганында хезмәт күрсәтәләр. Апасы пенсиягә чыккач, Нурания апа өч ел буена өч авылда да берүзе эшли.

“Фельдшер эше – солдат хезмәте ул. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ярдәмгә килергә әзер булырга кирәк. Төн уртасында да чыгып киткән чаклар бик күп булды. Иремә рәхмәт. Теләсә кайчан машинада илтеп кайта иде.

Кешеләр бит бездән һөнәри ярдәм генә түгел, ә рухи ярдәм дә көтәләр. Бигрәк тә олы яшьтәгеләр проблемалары, кичерешләре белән уртаклашалар. Аларга сабырлык күрсәтергә, үзләрен тыңларга, киңәш белән ярдәм итәргә, тынычландырырга кирәк. Татар халкы: “Яралы җанга яхшы сүз дә – дәва”, – дип юкка гына әйтми бит. Шуңа күрә кешеләрне җылы сүз белән дә дәвалый белергә кирәк. Шулай булганда аларның күңеле күтәрелә, хәлләре яхшыра, тизрәк терелләләр.

Эшемне бик яратып башкардым мин. Ә инде кешеләрнең терелүен күрү без, медицина хезмәткәрләре, өчен зур бәхет һәм шатлык булып тора. Халык онытмый, хәзер дә рәхмәтләрен белдерәләр, хәл белергә кереп чыгалар, шалтыратып, бәйрәмнәр белән котлыйлар. Алар бит чын күңелдән рәхмәт әйтәләр. Әнием: “Бер рәхмәт мең бәладән коткара”, – дия торган иде. Аллаһы Тәгалә шушы кешеләрнең ихлас рәхмәтләрен, изге теләкләрен кабул итеп тә, миңа Үз ярдәмен бирә торгандыр, дип уйлыйм”, – дип сөйли Нурания Абзалова.

Милләттәшебез медицина эшчеләре, югары профессиональлектән тыш, мәрхәмәтлелек, түземлек, кешелеклелек, хөрмәт кебек сыйфатларга ия булырга, кеше хәленә керә, аларны тыңлый белергә тиеш, шул ук вакытта таләпчәнлек тә кирәк, дип саный.

Хезмәтенә күрә – хөрмәте. Нурания Абзалованың лаеклы эшенә югары бәя биреп, үзен күп санлы Мактаунамәләр белән бүләкләгәннәр. Самар өлкәсенең һәм Россия Федерациясенең сәламәтлекне саклау министрлыклары тарафыннан бирелгән Мактаунамәләре дә бар аның. “Ел профессионалы” бәйгесендә “Самар өлкәсенең иң яхшы фельдшеры” номинациясе, ә “Халык тануы” конкурсында “Иң яхшы земство фельдшеры” номинациясе лауреаты да ул. Самар өлкәсе Губернаторының Мактаунамәсен дә кадерләп саклый Нурания апа. Ә 2020 елда аңа “Самар өлкәсенең Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре” исеме бирелә.



### “МИНЕМ ӨЕМ НИ ХӘЛДӘ?”

Нурания Абзалованың эшчәнлегенә, аның активлыгына сокланмый мөмкин түгел. Ул бит әле – “Әлифба” китабының авторы, татар мәгарифен үстерүгә бәяләп бетергесез зур хезмәт керткән танылган шәхес Сәләй Гатат улы Вагыйзовның туган авылы – Татар Байтуганында аның хөрмәтенә йорт-музей ачкан кеше.

Сәләй ага Вагыйзов һәм аның хатыны, хезмәттәше Рәмзия апа Вәлитова – татар мәгарифенә 50 елдан артык хезмәт иткән “Әлифба”ның һәм 40ка якын башка уку-укыту әсбапларының авторлары.

**“Нурания апа, мин – мәктәптә Сәләй ага Вагыйзов белән Рәмзия ханым Вәлитова төзегән “Әлифба”ны укып үскән кыз бит. Шуңа күрә бу тема миңа да бик якын. Шушы бөек шәхес хөрмәтенә музей ачу идеясе ничек барлыкка килде? Бу күләмле эшне ничек башкарып чыга алдыгыз?”** – дип сорадым милләттәшебездән.

Ул бәйнә-бәйнә сөйләп китте:

“1998 елда Татарстан телевидениесеннән бер тапшыру күрсәттеләр. Казан Кремлендә “Әлифба”ның авторы Сәләй Гатат улы Вагыйзовның 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтәләр. Сәләй әфәндегә сүз бирделәр, һәм ул үз чыгышында: “Мин – Байтуган малае”, – диде.

Дөрес, үзем бу тапшыруны карамадым. Миңа бу турыда авылдашым Ракия апа хәбәр итте. “Син ишеттеңме, “Әлифба”ның авторы Байтуган кешесе икән бит”, – диде ул. Шуннан мин туган авылының тарихын яхшы белүче әниемнән бу турыда сораштым. Ул миңа: “Почмак йортта Сәләй исемле бер малай үскән, Казан ягына киткән дә зур кеше булган икән. Тик син, балам, белер-белмәс моны сөйләп йөрмә. Башта дөресен бел. “Әлифба” – бик әһәмиятле китап бит ул”, – диде.

Шуннан мин бу турыда апама да сөйләдем. Элек авылыбызда татар мәктәбе бар иде, дигән идем бит. Апам шунда эшләгән укытучылардан “Әлифба” китабын табып алып кайтты. Авторлары Сәләй Вагыйзов һәм Рәмзия Вәлитова, дип язылган.

Шуннан мин, тәвәккәлләп, Сәләй әфәнде укытучы булып эшләгән



*Фәргат (сулдан уңга), Илюсә, Гөлфия, Нурания, Нәргизә, Илшат*

Арча педагогия көллиятенә хат яздым. Ике атнадан соң миңа Сәләй Вагыйзовтан җавап хаты килеп төште. Шатлыгым эчемә сыймады! Ул минем хатыма бик куанган. Бик күп сораулар язган. Туган авылында соңгы мәртәбә 1969 елда булган икән. Шулай без аның белән хат языша башладык.

Ә 1999 елда Сәләй ага безне Арчага "Әлифба" музеен ачу тантанасына чакырды. Без анда икенче көнне генә бара алдык. Сәләй әфәнде, камышлылылар, байтуганлылар килә дип, төне буе күз йоммаган. Хатыны Рәмзия апа безгә: "Үзе дә йокламады. "Рәмзия, син ничек йоклап ятасың, минем авылдашларым килә бит", – дип, мине дә йоклатмады", – дип сөйләде.

Безне Арча педагогия көллияте бусагасында каршы алдылар. Сәләй әфәндегә берничек тә 90 яшь бирерлек түгел иде. Төз гәүдәле, пинжәк, галстуктан. Беркайчан да онытылмаслык очрашу булды бу. Безнең белән Камышлыдан татар теле методисты Рәмзия Мирзаевна Сәлахова барган иде. Ул бик матур хатын инде. Сәләй Вагыйзов, безне күргәч, кайсыгыз Абзалова була, дигән сорау бирде. Без Рәмзия апа белән, алдан сөйләшкәндәй, бертавыштан: "Үзегез белегез", – дип җавап бирдек. Ә ул: "Мин беркайчан да кешедә ялгышмыйм", – диде. Шуннан Рәмзия Мирзаевна алдына килеп басты да, күзләренә туры карап: "Бик чибәр хатын, әмма сез Абзалова түгел", – ди. Аннары миңа карап: "Күзләре дә кечкенә, буе да кечкенә, ә үзендәге үткенлек, ә үзендәге күңел байлыгы", – диде. Безнең исебез китте. Кайдан шулай белә алгандыр инде ул!

Аннары Сәләй абый миннән: "Әлифба"ның кайсысын укыдың?" – дип сорады. "Әлифба"ны укымадым", – дигән җавап ишеткәч, аның күзләре мөлдерәмә яшь белән тулды. "Искиткеч, "Әлифба" укымаган кеше мине эзләп табарга булган. Мин олырак кеше көткән идем", – дип тә әйтеп куйды.

Димәк, аның күңеле кемнедер көтеп яшәгән. 90 яшьлек юбилеенда чыгыш ясаганда да: "Мин – Байтуган малае", – дип юкка гына әйтмәгәндер ул. Нинди дә булса нәтиҗәгә өмет иткәндер.

Гомеремә бер үкенечем бар. Шунда куна калмадым. Сәләй ага белән бу беренче һәм соңгы очрашуыбыз булды. 2005 елда ул якты дөньядан китеп барды...

Без аның белән шул көнне озак сөйләшеп утырдык. Ул миннән авыл урамнары, Песи тыкрыгы, Алтын тау турында сорашты. Безнең китәр вакытыбыз килеп җитте. Машинага утырабыз. Шулчак моңа кадәр безне каршы алган төз гәүдәле, 90 түгел, 70 яшь кенә бирерлек Сәләй аганың кинәт ничектер бәләкәйләнеп, картаеп киткәнен күрдем. "Кунып китегез инде", – дип үтенде ул. Калырга булган икән...

Ә машина кузгалып китәргә торганда, Сәләй абый яныма килде дә, яшь тулы күзләрен миңа төбәп: "Өемне сорамадым бит. Минем өем ни хәлдә?" – дигән сорау бирде. Аның шушы үзәкне өздергеч сүзләре әле дә колагымда яңгырый.

Кайтып барганда башыма сыйдыра алмадым – шундый шәхеснең безнең авылда туып-үскәне турында үзебездә белмиләр дә бит! Ә мин Арчада аның турында шундый сүзләр ишеттем бит. Андагы укытучылар миңа: "Авылыгыз дөньяга нинди бөек кешене бүләк иткән!" – диделәр.

Өе исән иде Сәләй аганың, әмма бикле, ташландык хәлдә...

Сәләй Вагыйзов белән очрашу, анда аның турында ишетеп кайткан сүзләр, мәшһүр якташыбызның: "Минем өем ни хәлдә?" – дигән соравы миңа тынгылык бирмәде. Күрешүебездән соң без Сәләй абый белән хат язышуыбызны дәвам иттек. Ул авылын бик сагына, йорты турында гел сораша иде.

Сәләй абый белән Рәмзия апаның язмышы бик аянычлы. Сәләй ага сугышта әсирлектә булган, аннары, Ватанга хыянәт итүдә гаепләнеп, 10 елга Печора елгасы тирәсендәге лагерьга җибәрелгән. Аның белән очрашкач: "Сәләй абый, шушындый авыр тормыш юллары үткәнсез, ничек түзә алдыгыз икән?!" – дип сорадым. "Яманлыкка гел яхшылык белән кайтардым", – дигән иде ул миңа. Көчлеләр генә шулай итә ала бит!

Ә бервакыт телевизордан Туфан Миңнуллинның чыгышын тыңладым. Ул анда шундый сүзләр әйтте: "Кеше чит җирләрдә нинди генә уңышларга ирешмәсен, аны туган ягында белмиләр икән, димәк, ул бернәрсәгә дә ирешмәгән".

Шуларның барысы турында да уйланып йөрдем мин. Ә 2012 елда ирем белән Бакирово шифаханәсенә ял итәргә баргач, анда "Туган авылым" бәйгесендә катнашып, авылыбыз, бездә Сәләй Вагыйзов туып-үскәне турында сөйләдем. Шулай дип әйтүем булды, андагы халык мине ялт-йолт фотога төшерә, сораулар яудыра башлады. Һәм бөтенесенең бер уртак соравы булды: "Сез аның өен сакладыгызмы?"

Шуннан мин йокымнан уянып киткән шикелле булдым. Сәләй абый үз йорты турында биргән теге сорауга тагын шушы сорау да өстәлде. Һәм

мин, җиң сызганып, эшкә керештем. Сәләй Гатат улы Вагыйзовның туган авылы – Татар Байтуганында, аның йортында мәшһүр якташыбызның музеен булдыру турында хатлар яза башладым – Бөтендөнья татар конгрессына, җәмәгать эшлеклеләренә, эшкуарларга һәм башкаларга, һәм башкаларга.

2015 елда Арча педагогия көллияте алдында "Әлифба"га һәйкәл куелды. Без ачу тантанасына бардык. Анда шагыйрь, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча комитет рәисе Рәзил Вәлиев та килгән иде. Мин аңа Татар Байтуганында Сәләй Вагыйзов музеен булдырырга теләвебез, моның өчен исәп-хисап счетын ачуыбыз, инициатив төркемне җитәкләвем турында сөйләп бирдем. Ул исә миңа Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановка хат язарга тәкъдим итте.

Шуннан Президентка хатны ничек языйм, нәрсә языйм икән инде, дип уйлап йөрим. Уй-фикерләр килми генә бит. Бер көнне эштән кайттым да телевизорны кабыздым. Ә анда диңгезне күрсәтәләр. Аның шаулавы! Президентка хат язарга шул диңгез шаулавы җитмәгән булган бит миңа, бу миңа илһам бирде! Уй-фикерләр үзеннән-үзе килә, сүзләр үзеннән-үзе туа тора.

Хатымда шундый сүзләр бар иде:

"Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич!

Мин сезгә изге Байтуган авылыннан язам. Иң борынгы авылларның берсе ул. Нигә изге, дисәгез, бездә "Әлифба" китабының авторы Сәләй Гатат улы Вагыйзов туган. Без аның белән күрештек. Бу беренче һәм соңгы очрашуыбыз булды. Аның: "Минем өем ни хәлдә?" – дигән соравы күңелемә бер генә дә тынгы бирми.

Милләтнең тамыры – тел, тел ачкычы – "Әлифба". Тел булмаса, милләт югала.

Тормыш – ул диңгез кебек. Анда төрле милләт дулкыннары. Башка милләт дулкыннары ачулык белән безне диңгездән куып чыгарсалар да, без, ярга чыгып, анда яткан ташларга бәрелеп, алардан көч алып, яңадан диңгезгә төшеп, татар милләте дулкыннары булып калабыз..."

Хатымны язып бетердем дә, күңелем тулып, елап җибәрдем.

Ә туган көнем алдыннан миңа Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең Россия Федерациясе төбәкләрендәге татар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү буенча урынбасары Марс Тукаев шалтыратып, бик тә шатлыклы хәбәр җиткерде: "Президент Рөстәм Миңнеханов Сәләй Вагыйзов музеен төзергә акча бүлеп бирү турындагы карарга кул куйды". Бу сүзләрдән соң түбәм күккә тиде.

Сәләй Вагыйзовның ташландык өен сүтеп ташлап, яңа өй төзедек. Шунда бар күңелем белән Аллаһы Тәгаләдән: "И, Раббым, шушы музейны гөрләтеп эшләтергә насыйп ит", – дип сорадым. Төзү – ул бер нәрсә бит, музейга сукмак өзелмәсен иде, дип борчылдым мин. Аллаһыга шөкер, музеебыз эшләп килгән шушы биш ел эчендә нинди генә төбәкләрдән нинди генә кешеләр килмәде. Унтугыз фән кандидаты, сигез профессор, "Халык укытучысы" исемен йөртүче мөгаллимнәр, Сәләй Вагыйзовның укучылары, яшьләр, балалар һәм башкалар.

Кызганычка, Сәләй әфәнденең үзенә туган авылын кайтып күрергә насыйп булмады шул. Ә аның улы – Камил абый безгә берничә тапкыр килде. Гаиләсе белән дә кайтты. Бик тыйнак кеше иде үзе. Гомере буе космонавтика өлкәсендә эшләгән. 2020 елда ул вафат булды.

Татар Байтуганы каршындагы тауга тимер калайдан ясалган "Әлифба" язуын урнаштыргач та килгән иде Камил абый. Бу язу Самар өлкә "Туган тел" татар җәмгыятенең президенты Ильяс Шәкүров биргән акчага куелды. Әлеге оешманың әгъзасы Фәһим Йосыпов оештыру эшләрен үз өстенә алды. Аларга мин бик рәхмәтлемен.

Шул вакытта килгәч, мин Камил абыйны кунак иттем. Үзен урманга җиләк җыярга алып бардым. Эх, нинди матур чаклар иде! Сандугачлар сайрый, урманның хуш исе башны әйләндерә. Шунда Камил абый миңа болай дип әйтеп куйды: "Беләсеңме, Нурания, әти миңа Байтуганның җиләкле аланнары турында сөйли иде бит. "Камил, моны мин нигә сөйлим – син бит моны беркайчан да күрмиячәксең", – дия иде".

Табигать турында сөйләшүебезне дәвам итеп, мин Камил абыйга ак каеннар яфрак ярган чакны үлеп яратуым турында әйттем. Шулчак ул балаларча елап җибәрде. Сәләй әфәнденең авылны нәкъ шул чакта бик күрәсе килгән булган икән бит...

Музеебызда Сәләй ага белән Рәмзия ханымның кулъязмалары, китаплары, киемнәре, аларның эш өстәлләре урын алды. Арчага барган саен буш кул белән кайтмадым мин.

Үземне бәхетле татар хатын-кызы, дип саныйм. Сәләй Вагыйзов миңа үз куллары белән тапшырган "Әлифба"ны аеруча кадерләп саклыйм.

Быел музей алдына асфальт җәйделәр. Районыбыз башлыгы Рафаэль Баһаутдиновка рәхмәтләр



***Нурания ханым (уртада) ире Фәргат, улы Илшат, кызы Илюсә, оныгы Альбина, апасының кызы Гөлия белән***

яусын. Ул һәрвакыт игътибарлы, ярдәм кулын суза. Музей алдындагы чишмәгә эшкуар Наил Кәлимуллин биргән акчага зур самавыр куйдык. Музей йортында чыршылар, агачлар утырттык, бик күп чәчкәләр үстерәм. Ирем, балаларым, апам Гөлфия белән җизнәм Мәсгуть бик зур ярдәм күрсәтеп торалар, үзләренә мин бик рәхмәтлемен.

Музейның бер бүлмәсе Сәләй Вагыйзовка багышланса, икенчесендә рус, татар, чуваш милләтләре тормышына кагылышлы экспонатлар, ветераннарыбызга, Бөек Ватан сугышына кагылышлы материаллар урын алды.

Шуны да әйтеп үтәсем килә – Сәләй Гататовичның бүлмәсен җиһазлауда Казанның Ш. Мәрҗани исемендәге 2 санлы татар гимназиясе директоры, Татарстан Республикасының Халык укытучысы, Атказанган укытучысы, Сәләй Вагыйзовның укучысы Камәрия Хәмидуллина һәм гимназиянең мөгаллимнәре бик зур эш башкардылар.

Матур традициябез дә бар – яшьләр туйларында кунаклары белән бергә музеебызга килеп китәләр.

Музейны булдыруда ярдәм иткән һәрбер кешегә, Президент Рөстәм Миңнехановка, Бөтендөнья татар конгрессына, районыбыз башлыгы Рафаэль Баһаутдиновка, Арча педагогия көллияте мөдире Гөлнара Гариповага, эшкуарларга, якташларыма, авылдашларыма Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын.

Арча педагогия көллиятенең элеккеге директоры, Сәләй ага белән Рәмзия ханымның бик якын дуслары Илдус Габдрахман улы Сәгъдиев дә безгә зур ярдәм күрсәтте. Музей ачылуга ул бик нык куанды. 2018 елда музейга килеп тә китте.

Эшкуар Марсель Йосыпов Арча педагогия көллияте каршына куелган "Әлифба" һәйкәленең миниатюрасын ясатты, ул музеебызда урын алды. Шулай ук ул Сәләй Вагыйзовның дәрәҗәле исемнәре язылган мемориаль такта һәм Сәләй аганың зур фотосурәтен ясатып, музей диварына элдерде.

Барысына да исәнлек, озын гомер, бәрәкәтле маллар телим. Кылган игелекле гамәлләре өчен Аллаһы Тәгалә савапларын арттырып кайтарсын, беркайчан да Үзенең ярдәменнән, киң рәхмәтеннән ташламасын".

Сәләй Вагыйзов музей-йортын ачып, аны гөрләтеп эшләткәне өчен Нурания апаны игътибарсыз калдырмыйлар.

Милләттәшебезгә «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» "Бөтендөнья татар конгрессы» халыкара Берлеге медале тапшырылган. Фатыйх Мортазин исемендәге Самар өлкәсе иҗтимагый премиясенә дә лаек булган ул. Өлкәбез мөфтие Талип хәзрәт Яруллин кулыннан Мактаунамә дә алган. Ә Арча районы администрациясе һәм Арча педагогия көллияте аны Рәхмәт хатлары белән бүләкләгән. Шулай ук Нурания апага Камышлы районы башлыгы Рафаэл Баһаутдинов тарафыннан «Район алдындагы казанышлары өчен» медале һәм Мактаунамәләр тапшырылган.



### "КҮҢЕЛЕМНЕҢ БАР КӨЧЛӘРЕН КУЕП, ЯМЕН ТАБАМ АЧЫ ТОРМЫШНЫҢ..."

Талантлы кеше һәрьяклап талантлы инде ул. Нурания апа язу сәләтенә дә оста бит.

Әле сигезенче сыйныфта укыганда, 1975 елда, район гәҗитәсендә аның беренче мәкаләсе басылып чыга.

Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышлап, "Никто не забыт, ничто не забыто" дигән иншасы белән конкурста беренче урынны яулый ул һәм аның язмасын гәҗитә битенә урнаштыралар.

Язу сәләте аңа әнисеннән күчкән икән. Ул, яза белмәсә дә, күңеленнән бик матур шигырьләр иҗат итә торган булган.

Нурания Абзалова Самар шәһәренең "Сәлам", "Бердәмлек" татар, "Волжский комсомолец", "Социальная газета", "Самара сегодня" рус гәҗитәләре белән хезмәттәшлек итә. "Ватаным Татарстан" гәҗитәсенә дә мәкаләләр язгалый. Бу басмалар үткәргән төрле конкурсларда катнашып, еш кына беренче урынны яулый. Әйтергә кирәк, татар телендә дә, рус телендә дә яхшы яза ул.

Нурания һәм Фәргат Абзаловлар ике бала – Илюсә белән Илшатны тәрбияләп үстергәннәр. Дүрт оныклары – Альбина, Алсу, Ильяс, Инсаф әби-бабалары өчен зур куаныч булып торалар. Альбина, әбисе эзеннән китеп, табиб һөнәрен сайлаган, медицина университетының өченче курсында белем ала.

"Кызыбыз белән улыбыз, Аллаһыга шөкер, тәртипле булып үстеләр, йөзебезгә кызыллык китермәделәр. Алар безнең – ныклы таянычыбыз. Динебез Ислам таләпләрен үтәп яшәргә тырышалар. Киявем Нияз белән киленем Нәргизә дә безгә үз балаларыбыздай якын. Кода-кодагыйларыбыз – бик яхшы кешеләр. Тәүфыйклы, акыллы, уңган, кешелекле балалар тәрбияләгәннәре өчен без аларга бик рәхмәтле", – ди Нурания апа.

**"Тормышыгызда иң бәхетле вакыйгалар нинди булды?" –** дип кызыксындым аңардан.

"Әти-әни исән чаклар иң бәхетле вакытлар иде. Аларның тормыш мәктәбен үтмәсәк, шушындый уңышларга ирешә алмас идем. Үзләрен догадан калдырмыйм. Балаларның, оныкларның исән-сау булып тууы – бик тә зур бәхет.

Гомумән, тормыштагы һәр мизгелне татып яшәү – минем өчен бәхет. Әниемнең шундый сүзе бар иде: "Һәр аткан таңны куанып каршы ал, кояш батканда, дога кылып, озатып кал". Тормышның һәр мизгеленең тәмен тоеп, булганына канәгатьлек күрсәтеп, Раббыбызга

шөкер кылып яшәргә кирәк.

Күңел байлыгы булу да – бәхет. Күңел байлыгы бар икән, аны башкаларга да өләшеп була.

Сәләй ага Вагыйзовның музеен ачуны да зур бәхеткә саныйм мин.

Бу соравыңа, Миләүшә, үзем язган шигъри юллар белән дә җавап бирәсем килә бит әле:

“Уйларымда кайтам яшьлегемә,
Гел чәчәкле, ямьле илемә.
Күз алдымда ак яулыклы әнием,
Әтием дә капка төбендә.
Якты дөньяларга туганга мин
Рәхмәтлемен сезгә мең кабат,
Күңелемдә изге сүзегез яши:
“Таш белән атучыга, кызым,
Син аш белән ат”.
Шулай итәм дә гомер агышында,
Әллә шуңа табам уңышын.
Күңелемнең бар көчләрен куеп,
Ямен табам ачы тормышның.
Газизләрем күчте мәңгелеккә,
Изге эзләр безгә калдырып.
Күңелемдә яши якты хыял –
Без дә көчә алсак иде ул илләргә,
Балаларга калдырып шундый
яктылык”.

**“Нурания апа, намазга да баскансыз икән. Моңа кем яисә нәрсә этәргеч бирде?”**

“Апам һәм җизнәм белән без 1988 елдан бирле бер йортта яшибез. Апам күптән намаз укый. Аның янына кергән саен, ул миңа: “Сеңелем, намазга басарга кирәк. Аллаһы Тәгалә сиңа бу дөньяда бөтен нәрсәне дә бирде. Син дә Аңа рәхмәтле булырга, Аның таләбен үтәргә тиеш”, – дип килде. Нәкъ апам мине намаз укырга өйрәтте, аңа моның өчен бик рәхмәтлемен. Чыннан да, бөтен нәрсә – Аллаһы Тәгаләдән бит. Барысын да Ул гына бирә. Намазга басканыма куанып бетә алмыйм”.





*Фәргат һәм Нурания Абзаловлар оныклары белән*

**“Тормышта кемнәргә таянып яшисез?**

“Иң беренче, Раббыбызга таянам. Безне эти-әни дә шулай өйрәттеләр. Ирем Фәргаттән башка тормышымны күз алдына да китерә алмыйм. 42 ел бергә без. Ул булмаса, мин бернәрсәгә дә ирешә алмас идем. Ирем һәрвакыт янымда, һәрвакыт ярдәм итә. Дөреслекне яратучы, бер дә алдый белми торган кеше. Мин аны бик хөрмәт итәм. Өстәвенә, бик уңган да. Нәселе шундый аның. Умартачы династиясен дәвам итүче дүртенче буын ул. Мине дә умартачы серләренә өйрәтте. Менә инде 30 ел умартачылык белән шөгыльләнәбез.

Балдан, аны сатып алган табыштан башкаларга да өлеш чыгарабыз. Күп балалы гаиләләргә ярдәм итәбез. Кләүле районының Черный Ключ авылындагы картлар йортына даими рәвештә булышабыз. Иремә рәхмәт, беркайчан да: “Бирмә”, – димәде. Әнием дә: “Кая барсаң да, буш кул белән барма”, – дия торган иде. Кем ярдәм сорап килә икән, берсен дә борып җибәрмибез. Юмарт кешегә Раббыбыз аннары малны арттырып бирә ул. Аллаһы Тәгалә юмарт кешеләрне ярата. Ул: “...әүвәл юмартлар Җәннәткә керсеннәр...”, – дигән бит.

Ирем турында сүз кузгаткач, бер мөһим нәрсәне әйтмичә булдыра алмыйм – Сәләй Вагыйзов Фәргатнең бабасының ике туганы булып чыкты бит!

Балаларым, апам Гөлфия белән җизнәм Мәсгуть тә – ышанычлы терәгем. Дусларым күп булмаса да, алар гомерлек. Байкалда яшәүче дустым Гөлсинә, Шенталыда гомер итүче иптәшем Люда – таянырлык кешеләрем”.

**“Нурания апа, сезнең буш вакытларыгыз бер дә калмыйдыр инде?”**

“Андый чаклар килеп чыкса, мәкаләләр язам, китап укыйм. Чәчкәләр үстерергә, тәмле ашлар пешерергә яратам мин. Хәл-әхвәл белергә, әби-чәбиләрнең күңелен күрергә, кешеләрне туган көннәре белән котларга яратам”.

**“Тормышыгыздан канәгать булып яшисезме?”**

“Аллаһыга мең шөкер, бик канәгатьмен. Мин – бик бәхетле хатын. Бәхет – ул исән-сау, ирең, бала-оныкларың, туганнарың янында булып, алсу таңнарны каршы алып, үз аягыңда йөреп, кешеләргә ярдәм итеп, газиз милләтемә хезмәт итеп гомер итү. Алга таба да Раббым шулай яшәргә язсын”.

**“Амин, Нурания апа. Бәхетегез кимемәсен”.**



*Сабантуй в Старом Фейзуллово. Мать Сергей Ахметовича, Сергей и его брат*

# СИЛА СЕЛА – В ЕГО ЛЮДЯХ

***В прошлой истории села Старое Фейзуллово хватает всего – трудностей на грани человеческих возможностей, а также успешных дел и всевозможных упущений и промахов***

**Фарид ШИРИЯЗДАНОВ**

Село это нельзя назвать ни большим, ни маленьким. Но для того, чтобы быть отдельной, самодостаточной хозяйственной структурой, там не хватало земельных угодий. Поэтому местный колхоз то присоединяли к соседнему, действующему в селе Степная Шентала, то отсоединяли обратно.



*Сергей Ахметович в детстве*

При этом хозяйственному подразделению села Старое Фейзуллово то придавали статус бригады, то там снова восстанавливали отдельный колхоз, не желая быть подбрюшьем у соседей.

Когда в стране начались крутые перемены и на корню разрушалось народное хозяйство, колхоз «Шенталинский», куда входило село Старое Фейзуллово, разделили и сформировали три самостоятельных колхоза.

К сожалению, разделение произошло без конкретных согласований и расчетов, необходимых для дальнейшей самостоятельной деятельности каждого из них. Как принято называть в данном случае, «разрезали по живому».

В итоге ситуация, сложившаяся во вновь созданном колхозе «Рабочий», тогда казалась безвыходной: денег нет, корма для содержания скота хватало всего на несколько дней. Встали всевозможные проблемы, решить которые оказалось непросто. Например, имея в колхозе чуть более 1700 гектаров пахотной земли, нельзя было содержать то поголовье крупного рогатого скота, которое имелось в хозяйстве.

Казалось, что перспективы нет и крах колхоза неизбежен. Тогда никто из членов правления и специалистов не захотел возглавить вновь созданный колхоз.

В этой ситуации руководство района рекомендовало на пост председателя Сергея Ахметовича Бисултанова.

В ходе поиска материалов для написания книги об истории села мы обратились к нему с просьбой рассказать о том, что происходило в период его руководства колхозом.

Встреча эта превзошла все наши ожидания. Беседа, длившаяся три с половиной часа, прошла как на одном дыхании. Поскольку по национальности он чеченец, оказалось, что, как и все кавказцы, он обладает потрясающей волей, крепким духом и удивительными деловыми качествами. При этом он прекрасно владеет культурой речи, умением располагать к себе и обладает серьезной силой убеждения.

А это бывает только у людей с крепким внутренним стержнем и полностью уверенных в себе, в своих возможностях. Кажется, что при общении с ним невозможно не соглашаться, либо сомневаться в чем-то, так как слова его всегда выверены, четко аргументированы и убедительны.

В ходе беседы мы получили исчерпывающие ответы на интересу-



*Фото детей из села Старое Фейзуллово*

ющие нас вопросы:

**– Сергей Ахметович, во-первых, хочется узнать более подробно о вас: откуда родом, как попали в эти края и как стали председателем колхоза?**

– Родился я в Казахстане. Затем переехали в город Грозный, и двадцать лет я жил там. Два года служил в армии в Польше.

Окончил индустриально-педагогический техникум в городе Волгограде. Заветной моей мечтой было стать прорабом, строить высотные дома и серьезные сооружения. Поскольку у себя на родине я не видел особых перспектив, мне посоветовали поехать в глубинные районы России для того, чтобы набраться опыта и, познав премудрости этой профессии, вернуться к себе на родину и продолжать там работать. Приехал в город Куйбышев на 2–3 года, и судьба сложилась так, что задержался на сорок лет. Имею пятерых детей. Так я в составе бригады строителей попал в колхоз «Заветы Ильича», расположенный в селе Красное Поселение Кошкинского района. Заметив мои деловые качества, предложили стать заместителем председателя колхоза с правом подписи на текущих документах. Затем поступил в Куйбышевский сельскохозяйственный институт и заокончил его.

В процессе работы наряду с тем, что активно вели строительство, я всегда прислушивался к просьбам и чаяниям населения и всячески старался помогать им, особенно пожилым и нуждающимся в помощи. Во-первых, это является одним из основополагающих принципов чеченского народа и традиций, на основании которых мы воспитаны с детства. Во-вторых, сельское общество – это как живой организм, и все, что происходит там, – взаимосвязано. И, наконец, жить, делая людям добро – это принцип моей жизни.

**– А как вы оказались председателем колхоза «Рабочий»?**

– Поработав в колхозе «Заветы Ильича», я стал членом партии, приобрел приличный опыт работы в профессиональном плане и в руководстве с людьми. Со временем, подумав, решил вернуться на свою родину. Узнав это, в районном комитете КПСС мне предложили стать председателем одного из колхозов в районе. Предложили несколько вариантов.



*Начало работы в совхозе «Заветы Ильича», фото с директором школы села Красное Поселение*

Хотя я упорно отказывался, в конечном итоге вынужден был согласиться. Ведь отказываться и идти против воли партии – это тогда казалось делом немыслимым и бесперспективным. Исключение из партии тогда считалось большим позором, даже не считая соответствующие печальные последствия.



*По краям дочки Сергея Ахметовича а рядом девочки из села Старое Фейзуллово. Сабантуй*

Из предложенных вариантов я выбрал колхоз «Рабочий», расположенный в селе Старое Фейзуллово, где проживает мусульманское население. Я знал, что мы, мусульмане, всегда найдем общий язык.

Прибыв в село, я пришел в ужас, видя положение дел и оценив сложившуюся там ситуацию. Так называемое правление колхоза размещалось в маленьком здании возле дороги, где ранее хранились газовые баллоны. Из мебели там были деревянный стол, скамейки и старенький телефон. На полу валялись кучки каких-то бумаг.

– Бухгалтерами и экономистами работали молоденькие девчата. Когда я обратился к ним, желая ознакомиться с положением дел в хозяйстве, они пустились в слезы. Я успокаивал их и говорил, что все будет хорошо. Однако оказалось, что фуражного зерна в колхозе осталось всего на несколько дней. Да и дальнейшая перспектива развития колхоза не радовала. Как можно развернуть хозяйственную деятельность, когда колхоз имеет всего чуть больше 1700 гектаров пахотной земли?!

Не было зернохранилищ, мастерских для ремонта техники. Условий для труда механизаторов и животноводов тоже не было. Процветали воровство, вседозволенность и пьянство. Одним словом, все здесь предстояло с головы поставить на ноги, то есть начать с нуля.

Поскольку мы потомки тех, кого веками воспитывали суровые горные условия, и наш народ сохранил свое достоинство, несмотря ни на какие удары судьбы и жестокие испытания, я твердо решил, что сможем выправить положение. Эту уверенность я старался вселить и в души людей.

Постепенно все налаживалось. Купили молоковоз, затем автома-



*Встреча с генеральным директором АвтоВАЗа – В. Каданниковым*

шину ЗИЛ-130 и другую необходимую технику и оборудование. Начали строить жилье и так далее.

**– Вам приходилось проявлять жесткость для устранения безобразий укорененных в хозяйстве. При этом как удалось вам заслужить еще и уважение среди населения?**

– Не зря говорят: «Ничто не дается так просто и не ценится так дорого, как уважение человека». Уважение старших, верность своему слову, сохранение чести и достоинства – это в крови кавказского народа. Да и в исламе тоже много внимания уделяется добрым взаимоотношениям людей. Никогда нельзя забывать и то, что добро всегда отзывается добром, а зло – возвращается злом.

Когда есть возможность, я всегда старался и стараюсь помогать людям. Заслужить уважение людей, особенно если ты являешься руководителем, – дело трудное. Это добывается годами, и его необходимо постоянно подкреплять. А потерять уважение можно в одно мгновение.

Творить добро – не всегда просто. Например, когда человек оступился и совершил проступок, тебе предстоит наказать его. Но при этом нельзя забывать, что может пострадать его семья. Иногда приходится предстать перед серьезным выбором, даже спорить с членами правления и убеждать их, что уметь прощать – тоже дорогого стоит.

**– Если обратиться к цифрам, как вы можете проиллюстрировать динамику хозяйственной деятельности в вашу бытность председателем колхоза?**

– Не имея элементарной хозяйственной документации, когда трудовой коллектив деморализован и у людей отсутствует вера в будущее, процветает пьянство и воровство, непросто начинать с нуля. При этом сначала надо в своем мозгу создать образ того, к чему следует стремиться. А потом – неуклонно идти к нему. Я постоянно следил за производственными показателями и всегда говорил: «Не снижать, а всегда надо повышать показатели производства!»



*Сергей Ахметович с сыном*

Труднее всего – настраивать людей на рабочий лад и вести борьбу с пьянством и несунами, когда эти пороки укоренились и стали нормой.

Однажды вижу, что скотник везет домой силос. На мое замечание он невозмутимо говорит: «Ну и что, я же работаю на ферме и имею право, жалко, что ли?!»

А я ему говорю, что кассир тоже работает на кассе, а если она тоже станет пачками таскать деньги?

Я предлагал по низкой цене выписывать корма, даже организовывал их подвоз к домам.

А что касается динамики роста экономики, то мы старались наращивать производство, так как от этого зависело не только состояние колхоза, но и уровень жизни колхозников, их благосостояние.

**– В настоящее время село в сложном положении. Как вы считаете, имело ли оно тогда перспективу для развития? И что можно сделать сейчас, чтобы предотвратить его распад?**

– При желании можно все сделать. Возможности были тогда, они есть и сейчас.

В то время, конечно, были более серьезные возможности. Например, тогда автозавод ВАЗ брал шефство над хозяйствами Кошкинского района, так как проводилась политика поддержки сел и сельскохозяйственного производства, развернутого там.

По долгу службы мне приходилось налаживать контакты с руководством завода. Мне лично были знакомы руководители различных подразделений, вплоть до генерального директора.

Завод ВАЗ тогда поддерживал связь с итальянскими коллегами. Однажды мне посчастливилось познакомиться и тесно пообщаться с итальянцами. В то время в нашем хозяйстве и хозяйствах района практиковали выращивание сахарной свеклы, которую возили в город Нурлат.

В процессе беседы с ними я высказал мысль, что неплохо бы организовать переработку свеклы у себя в районе. Также сказал, что в районе имеется хозяйство, где выращивают яблоки, и было бы неплохо организовать переработку и там.

Итальянцы заинтересовались ими и предложили нам приехать в Италию для ознакомления с процессом производства сахара, яблочного уксуса, вина и детского питания. Условия были такие: мы приезжаем туда на свои деньги, а проживание там и обратная дорога будет за их счет.

Со временем пришло и приглашение. Но, как у нас издавна заведено в России, все новое, необычное и неординарное всегда принимается на штыки, и наталкиваешься на глухую стену непонимания. При этом тут же возникают различные препоны.

Но главная беда в том, что противодействие исходит от тех, кто родился и вырос там. Казалось бы, ведь они сами должны быть заинтересованы в этом больше всех! Но увы. В районе тоже не поддержали эту инициативу. Но больше всего я боялся того, что если не получится претворить в жизнь эту идею и я зря потрачу средства колхоза, экономика которого тогда еще была довольно в сложном положении.

**– За короткое время, в течение каких-то пяти лет вы с нуля подняли на ноги хозяйство и сделали для села столько, сколько не было сделано ни до вас, ни после. Как это смогло произойти?**

– Главная задача руководителя – умение настроить коллектив на рабочий лад, особенно специалистов и руководителей среднего звена. При этом надо обладать силой убеждения, чтобы люди с уверенностью могли идти за тобой. Все зависит еще от того, сумеешь ли ты вселить в людей надежду на будущее и уверен ли ты в том, что сможешь довести начатое дело до конца.

**– Всевышний наделил кавказские народы крепким духом, упорством в достижении целей, особой статью и создал их прирожденными борцами. Можете ли провести аналогию между спортивными приемами и случаями из жизни?**

– Мне вспоминается случай, когда шли соревнования по вольной борьбе, организованные в стадионе города Грозного. Случилось так, что моим соперником оказался темнокожий. В начале поединка и я, и он долго прицениваются друг к другу, не делая особо резких движений. Тут я слышу возгласы: «Ну чего ты ждешь, давай, хватай его!» Тут я схватил его, поднял и бросил на ковер.

В жизни то же самое – и особо спешить нельзя, упускать момента – тоже.

**– Среди проделанных дел какие вы считаете более важными, которыми можете особо гордиться?**

– Сделано, конечно, много. Но поскольку я являюсь строителем по профессии и призванию, считаю, что наиболее важными являются объекты, построенные нами. Особенно хочу отметить строительство мечети. Думаю, что все люди, живущие в типовых домах, построенных нами, тоже долгие годы будут вспоминать нас добром, – сказал Сергей Ахметович Бисултанов.

– Несмотря на то, что по историческим меркам события, происходившие в колхозе «Рабочий», созданном на базе села Старое Фейзуллово, прошли совсем недавно, сведений об истории его развития и деятельности колхоза сохранилось мало. А те, кто владеют мало-мальской информацией, делятся ею неохотно, так как они сейчас особо радуют.

Но период, когда колхозом руководил Сергей Ахметович Бисултанов, ознаменован значительными успехами и важными событиями, о которых народ вспоминает с благодарностью.




*Сергей Ахметович с сыном и женой*



# ЯҺУДИННАР - СОКЛАНДЫРГЫЧ НӘСЕЛ

***Элгәре тормыш шактый авыр һәм катлаулы булса да, һәр гаиләдә 5 - 6 бала тәрбияләнүе гадәти хәл иде. Кияргә - рәтле кием, ашарга - ризык, китап-дәфтәр дә җитешмәгән, талдан яки шырпыдан санау таякчыклары ясап укыган гади авыл балаларының, югары дәрәҗәләргә ирешеп, галимнәр булуы – гаҗәеп күренеш.***
***Габделхәй абый һәм Сәрвәрия апа Яһудиннар гаиләсе тарихында бу хәл ачык күренә. Аларның 70 елдан артык бергә матур яшәп, гыйбрәтле тормыш юлы үтүләренә сокланмыйча һич кенә дә мөмкин түгел.***

**Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ**

Афзалетдин улы Габделхәй ага Яһудин Самар өлкәсенең Кошки районындагы Иске Фәйзулла авылында 1927 елның 15 августында дөньяга килә.

Тормыш юлындагы вакыйгаларның күбесе онытылса да, сугыш еллары аның хәтеренә нык сеңеп калган. 1941 елда игеннәр яхшы уңса да, таза егетләр, ирләр сугышка китә. Бөтен авырлыклар яшүсмерләр, хатын-кызлар һәм картлар җилкәсенә төшә. Сугыш яу кырларында гына түгел, тылда да иксез-чиксез бәлаләр, зур югалтулар китерә. Корчаңгыдан, ябырылган төрле чирләрдән атларның күбесе үлеп бетә. Габделхәй абзый кебек яшүсмерләргә дә, үгезләр, сыерлар җигеп, җир эшкәртергә һәм авыл хуҗалыгындагы барлык авыр эшләрне башкарырга туры килә.

Кырларны саранча баса, трахомадан халыкның күзләренә зур зыян килә, араларында сукыраючылар да күп була. Халык ачлык-ялангачлыктан, авыр эштән һәм әледән-әле килеп чыккан төрле чирләрдән интегә. 17 яше тулгач, 1943 елда Габделхәй ага да сугышка китә һәм фронтка кергәндә аларның эшелонын немецларның Кенигсберг шәһәре (хәзер Калининград) янында бомбага тоталар. Күп халык үлә, ә ул, каты яраланса да, исән кала. Госпитальдә дәваланганнан соң сугышка яраксыз, дип табыла. Аягына да баса алмаган килеш авылына кайта һәм аңа озак вакыт дәваланырга туры килә.

1947 елда Камышлы педагогия училищесын бетереп, Җүрәйгә юллама буенча башлангыч мәктәп укытучысы булып килгән Сәрвәрия Мәҗитова белән таныша һәм аңа өйләнә.

Габделхәй ага башта – Чистай педагогика училищесын, аннан соң Казан Дәүләт университетының тарих факультетын читтән торып тәмамлый. 1953 елда аны Аксубай районындагы Яңа Ибрай авылына башлангыч мәктәп укытучысы итеп эшкә җибәрәләр. Озак та үтми, аны – Урмандаево авылы мәктәбенә директор, соңрак Иске Тат.-Кармәт 8 еллык мәктәбенә завуч итеп билгелиләр.

Еллар авыр, белемле кешеләр аз булганга, җирле колхозның партия оешмасын җитәкләүне дә аның өстенә йөклиләр. Эшен уңышлы гына алып барганда аны, райкомга чакырып, Яңа Үзи авылындагы “Ышанычлы юл” колхозына рәис итеп җибәрәләр. Тора-бара ул колхозга тагын бер артта сөйрәлгән хуҗалыкны кушып, бу яңа хуҗалыкка «Дуслык» исеме бирәләр.

1960 нчы еллардагы дәвер – ул сугыш авырлыклары җиңелеп, тормыш алга атлый барган вакыт. Ул чорда колхоз-совхозларга яңа техника кайтарыла башлый. Андагы эшләрне фән казанышларына, яңа технологияләргә нигезләп алып бару бурычы алга куела.

Ләкин авыл хуҗалыгы белгечләре, укымышлы җитәкчеләр ул чакта әле аз, юк дәрәҗәсендә булганга, мәктәп директорлары кебек укымышлы кешеләрне колхоз рәисләре итеп сай-



лау да гадәти хәлгә әверелә. Әлбәттә, бу авыл хуҗалыгын күтәрүгә, фәнни нигезләгән технологияләр кертүгә юнәлгән хәлиткеч бер чара була. Габделхәй абзый Яһудинның көтмәгәндә укытучыдан колхоз рәисенә әверелүе менә шуңа бәйләнгән дә инде. "Габделхәй ага үз заманында алдынгы кешеләр белән тиз таныша, татарлар, урыслар, чувашлар белән аларның ана телләрендә сөйләшеп, бик тиз уртак тел таба белгән, булганны җимерүче түгел, ә төзүче кеше иде", – дип искә ала колхозда озак еллар баш бухгалтер булып эшләгән Фәрит Гатин.

"Яңа рәис тиз арада күп авыл яшьләрен укырга, хуҗалыкка кирәк булган профессияләрне алырга җибәрде, аларны колхозда эшкә урнаштырды. Үзе йөри торган Волга Газ-21 машинасын бульдозерга алыштырып, яхшы юллар төзергә тотынды. Ульяновск, Нижний Тагилдагы завод директорлары белән танышып, колхозга яңа машина кабиналары, запас частьләре, авыл хуҗалыгы техникасы оешмасы аша техника кайтаруны оештырды, электросварка аппараты кайтартты, колхозчыларны он белән тәэмин итү өчен тегермән ясатты. Ул вакытта мондый эшләрне башкарып чыгучы колхоз җитәкчеләре бик сирәк иде",– дип сөйли Фәрит Гатин.

Сыер саварга – чиләк, мал ашатырга сәнәк тә җитешмәгән вакытлар акрынлап артта кала. Аның әлеге








хуҗалыкта 10 елдан артык эшләү дәверендә савым сыерлары саны 100 баштан 1200 гә, ә мөгезле эре терлек 2700 башка җитә. Типовой терлек фермалары, он тегермәне, ябык ашлык тогы, пилорама, ит комбинаты, кече элеватор, ашханә төзелә. Машина-трактор паркы үсә. Артта калган ике колхоз берләшкәч, татарлар һәм чувашлар дус, бердәм булып эшлиләр.

Нәтиҗәдә алты авылны берләштергән һәм "Дуслык" дип аталган яңа колхоз акрынлап алдынгылар сафына баса. Бу колхоз карамагына кергән авылларда торак йортлар, таш кибет, юллар салына. Производство күрсәткечләре һәм халыкның көнкүреш шартлары үсеш ала. Тора-бара Габделхәй агага лаеклы рәвештә "Татарстанның Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелә.

Ул – "За Победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941 – 1945гг." һәм башка күп дәүләт бүләкләре кавалеры, Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре. Татарстан Республикасы Президенты исеменнән кул сәгате, ТР авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән. Аксубай муниципаль районы, Нурлат шәһәренең Хөрмәтле гражданины. Аның исеме Аксубай район үзәгендә һәм Нурлат муниципаль районының Чув. Менча авылы урамнарына бирелгән.

Үткәндәге эшләр, тормыш хәлләре турында сөйләшкәндә ул:

– Өйдә тәртип булмаса, авыл хуҗалыгын да, җәмгыять эшләрен дә уңышлы алып барып булмый. Ирне ир иткән дә, хур иткән дә – хатын, диләр. Аллаһыга шөкер, хатынымнан уңдым мин!

Шулай да, хатын-кыз муен булганда, ир кеше баш була белергә тиеш. Муен ничек боргаласа да, ир кешегә башны тота белергә кирәк. Үзара аңлашу булмаганда, тормыш ул туза, какшый. Ир белән хатын икесе дә бер сүздә булганда гына, тормыш уңай була һәм алга бара. Безнең гаиләдәге эшләр менә шулай барды. Аллаһыга



шөкер, балаларыбызның тормышында да шундый ук хәл.

Безнең кебек, 70 елдан артык тату гомер итәр өчен мәхәббәт, бербереңә хөрмәт булуы кирәк. Шулай булмаганда, тормышның бәрәкәте югала, – дип сөйли Габделхәй абзый.



Аның хатыны Сәрвәрия апага карата булган мәхәббәт хисләрен бик кадерләп саклый. Гаилә альбомында сакланган фоторәсемнәрдә Сәрвәрия апаның йөзеннән нур бөркелә сыман. Аның тыныч һәм мөлаем йөзендә тормышчанлык һәм күзләрендәге акыл тирәнлеге ачык күренә.

Сәрвәрия ханым Яһудина 1927 елда Ульяновск өлкәсенең Әбдери авылында Мәҗитовлар гаиләсендә беренче бала булып туа һәм алты балалы гаиләдә тырышчан, өлгер булып тәрбияләнә.

Ул үз гомеренең 45 елын балалар укытуга багышлаган, Куйбышев өлкәсенең Иске Җүрәй, Татарстанның Чәтрән (Яңа Ибрай), Урмандәй (Урмандеево), Яңа Үзи авыллары мәктәпләрендә, Сталин поселкасында эшләгән.

Шул вакытта үзенең җиде баласының да беренче укытучысы булган, аларга киләчәктә ныклы белем алуга төпле нигез салган. Балаларының барысын да тормышны сөеп, яшәүнең кадерен белеп яшәргә өйрәткән. Аның эшен югары бәяләп, үзенә “Татарстанның Атказанган укытучысы” дигән мактаулы исем бирелгән.

Әгәр дә Сәрвәрия апаның үз балаларына биргән тәрбияне аерым алып карасаң, аның гаилә педагогикасына тиешле бәяне әле тагын да югарырак, мактаулы исемнең дә тагын да затлырагын биреп булыр иде. Ул үз балаларын авыр чакларда да йомшаклык, йөрәк җылысы һәм ана мәхәббәте белән чорнап тәрбияли алган.

Бу гаиләдәге ана инстинктының кодрәтен, әһәмиятен һәм аның тәрбия өлкәсендәге серләрен бернинди Ушинскийлар, Сухомлинскийлар да аңлатып бирә алмастыр, мөгаен!

Сәрвәрия апа үскәндә үзе дә гыйбрәтле тормыш мәктәбе үткән. Гаиләдә өлкән бала буларак, күпсанлы энеләрен, сеңелләрен тәрбияләүнең төп авырлыклары да аның җилкәсенә төшкән.

Сугыш башлангач, ирегетләр юклыктан, аны, 15 яшьлек кыз баланы, тракторчылар курсына укырга җибәрәләр. Кечкенә буйлы кызның нечкә куллары белән үкереп торган тракторны “йөгәнләвен” күз алдына китерү кыен, әлбәттә. Ләкин нишлисең, сугыш ул әле сөяге дә ныгымаган, балалыктан чыкмаган яшьләр өстенә элгәре таза ирләр башкарган вазыйфаларны йөкләгән бит!

Ике ел тракторчы булып эшләгәч, әнисе аны Камышлы авылындагы педагогика училищесына укырга җибәрә. Укуын тәмамлагач, аны Кошки районындагы Иске Фәйзулла авылына эшкә юллыйлар. Менә шунда алар Габделхәй ага Яһудин белән танышалар да инде.

Габделхәй ага һәм Сәрвәрия апа сугыштан соңгы авыр заманда кавышып, төрле сынаулар аша үткәннәр. Бар булган авырлыкларны да җиңеп, алар эчтәлекле, матур һәм бәрәкәтле гомер кичергәннәр.

Габделхәй ага өлешенә сугыштан соң таушалган, тузган, хәерче хәлендәге колхозларны аякка бастыру юлында көнне-төнгә ялгап, бар куәткә бирелеп эшләргә туры килә.

Ә Сәрвәрия апа китаплар, дәфтәрләр җитмәгән чакта, өсбашларына кияргә киеме булмаган һәм туйганчы ипи дә ашый алмаган балаларны укыткан. Шуларның күбесе әле сугыш ятимнәре дә булганга, аларны юатып, үзләрендә укуга теләк уятырлык җан җылысы, ихтыяр көче табарга туры килә аңа.

Шул чакта керосин лампалары яктысында, тал чыбыгыннан таякчыклар ясап, санарга өйрәнгән укучыларының зур җитәкчеләр, галимнәр булып җитешүе могҗизага тиң күренеш түгелмени соң?!

Бар булдыгын, ихтыяр көчен мәктәпкә, җәмгыять һәм колхоз хәлләрен кайгыртуга биргән бу кешеләр үзләренең җиде баласын тәрбияләү өчен дә кайдан көч алдылар икән соң?!



Габделхәй аганың һәм Сәрвәрия апаның фоторәсемнәрен карасаң, усаллыкның, кырыслыкның эзе дә күренми. Анда тик ачык йөзләр, ягымлы һәм мөлаем карашлар, тирән акыл чагылдырган күзләр генә карап тора.

Шул фотоларны карагач, алар гаиләсе турындагы язмаларны укыгач, тирән кызыксыну хисләре туа, аларның гаиләсе турында әле тагын да күбрәк беләсе килә. Нәрсәгә бәйләнгән икән соң бу гаиләдәге тормыш һәм тәрбия уңышлыгының серләре?

Яһудиннар гаиләсе турында язылган истәлекле басмаларны укыганда һәм рәсемнәрен караганда бар җирдә дә аларның бер-берсенә карата булган мәхәббәте һәм тирән ихтирамы да аерым-ачык күренә. Ә боларның ясалма булуы һич тә мөмкин түгел бит!

Габделхәй аганы укытучы, мәктәп директоры, колхоз рәисе итеп билгеләгәндә авылдан-авылга күченеп йөрүләр дә алар гаиләсенә шактый күп авырлыклар китереп, ныклы сынаулар аша үткәрә.

Ул елларда авыл хуҗалыгын алып бару, бигрәк тә артта сөйрәлгән хуҗалыкларны уңай эзгә салу – ул бик җаваплы, авыр хезмәт. Бу чакта Габделхәй абзыйның гаиләсе аның үзенә ныклы терәк була. Авыл хуҗалыгын уңышлы алып бару өчен көчне дә ул менә шунда туплый.

Әлбәттә, җиде бала үстереп, аларны югары дәрәҗәләргә ирешерлек, чибәр һәм кешелекле шәхесләр итеп тәрбияләгән бу гаиләгә сокланмыйча һич тә мөмкин түгел.

Элгәреге ишле гаилә тормышының үз законнары һәм язылмаган көчле тәрбия чаралары булган шул. Анда хезмәткә мәхәббәт, олыларга хөрмәт, шәхси җаваплылык, мөстәкыйльлек, тормышчанлык һәм башка кыйммәтле күп нәрсәләр тәрбияләнә иде. Яһудиннар гаиләсендә туып- үскән балаларның җидесенең дә данлыклы шәхесләр булып танылуы күпләргә билгеле. Аларның үз фамилияләрен байрак итеп күтәреп, үз нәселләре белән горурланып, аның данын үстереп яшәргә тырышуларының сере тулысынча этиләре Габделхәй абзыйга бәйләнгән.









Габделхәй ага һәм Сәрвәрия апа Яһудиннарның гомер юлы Аксубай һәм Нурлат төбәкләре белән тыгыз бәйләнгән. Алар шунда олы хөрмәткә лаек булырлык, эчтәлекле тормыш юлы үткәннәр һәм халкыбызның горурлыгы булырлык балалар үстергәннәр. Болар:

Җәмил Яһудин – аларның олы уллары, ул Иске Җүрәйдә туган. Әтиләре башы-аягы белән колхоз эшенә бирелгәнлектән, йорт хуҗалыгын алып бару һәм аның үзеннән кече энеләрен-сеңелләрен тәрбияләү, аларга күз-колак булу җаваплылыгы, әлбәттә, аңа йөкләнгән була.

Ләкин иң авыры – аңа Сталин поселкасында торганда күрше авыл мәктәпләренә йөреп уку була. Бигрәк тә кыш көннәрендә. Унсигез чакрым араны җәяү үтү өчен төнге сәгать икедә торып, юлга чыгарга туры килә.

Армия сафларында хезмәт иткәч, аны юллама буенча эчке эшләр министрлыгы карамагына җибәрәләр һәм гади милиционер итеп хезмәткә алалар. Аннан соң ул Алабуга милиция мәктәбен һәм МВД СССР Академиясен тәмамлый. Тора-бара аны – Казандагы Ленин районының милиция бүлеге начальнигы урынбасары, ә 1984 елда Казандагы Идел Буе районы эчке эшләр бүлеге начальнигы итеп билгелиләр.

Әлбәттә, бу эштә аңа аеруча зур җаваплылык йөкләнә. Бигрәк тә "Казанский феномен" шаукымы киң җәелеш алганда. Ул чакта җинаятьчелек яшәрә һәм аның әлегәчә күренмәгән, яңадан-яңа формалары барлыкка килә.

Яңа эш алымнары кулланып, уңышлы эшләр башкарганы өчен аны үзәк аппаратка башта – бүлек начальнигы урынбасары, аннары Татарстан эчке эшләр министрлыгының җәмгыять куркынычсызлыгы милициясе начальнигы урынбасары итеп билгелиләр. Аның кул астында эшләгән хезмәткәрләр һәрвакытта үзен олы рәхмәт хисләре белән телгә алалар.

Дәүләт Советы депутаты булып сайлангач, ул Татарстан Республикасы Дәүләт Советында парламент контроле комитетын җитәкләгән, дәүләт бюджеты үтәлеше отчетын тикшеру алып баруны оештыра.

Икенче тапкыр сайлангында Дәүләт Советының "Законность, регламент һәм депутат этикасы" комитетын җитәкли. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Дәүләт Думасы утырышларында Татарстан Дәүләт Советы керткән канун проектлары буенча чыгышлар ясап, аларны яклап, бишесен федераль закон булып кабул ителүенә ирешә.

Җәмил Яһудин "Кайнар нокталарда" да булган. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, исемле кул сәгате, сугыш коралы белән бүләкләнгән. (Именное боевое оружие).

Ул – педагогия фәннәре кандидаты. Монография, ике китап, уку-укыту методик әсбаплары һәм 25 фәнни статьялар авторы, Татарстан Республикасының Атказанган юристы, педагогия һәм психология факультеты доценты.

Наил Яһудин – икенче уллары. Ул, Аксубай урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан химия технология институтында укып, аны уңышлы тәмамлый. Бишенче курста укыганда ук комсомол комитеты аны Татарстан ВЛКСМ обкомының студент отрядлары штабына җибәрә. Бернічә айдан ул комсомолның өлкә комитеты секторын җитәкли.

Институтны тәмамлагач, аны Казанга, КАМАЗ генераль дирекциясе представительствосына эшкә җибәрәләр. Анда ул төзелешнең төрле структуралары эшчәнлегенең үзара бәйләнешен булдыручы оешманы җитәкли. Ике елдан соң ВЛКСМ Үзәк Комитеты Наил Яһудинны КАМАЗдагы Бөтенсоюз удар төзелеш штабы начальнигы итеп билгели.

Бу вакытта КАМАЗ төзелеше штабы төрле проблемаларны хәл итә торган көчле үзәккә әверелә. Илнең төрле якларыннан җыелган яшьләрнең энтузиазмы искит-





– дип горурланып сөйли Наил Яһудин. Ул – Татарстанның Атказанган төзүчесе.

Шамил Яһудин – өченче уллары. Үзләре яшәгән авылдан ерактагы мәктәпкә йөреп, аны тәмамлагач, Казандагы химик-технология институтында укый. Ахырда ВЛКСМның Өлкә Комитеты аны Нурлат шәһәренә эшкә юллый. НУРБда бераз вакыт комсомол оешмасы секретаре булып кеч көчле була. Һәркем бу яшьләр шәһәрен әкияттәгедәй матур итеп төзү теләге белән янып яши.

Менә шундый күңел күтәренкелеген Наил Яһудин һәм аның командасы булдыра да инде. Яшьләр төзелеше булганга, андагы очсыз-кырыйсыз проблемаларны хәл итәргә туры килә аңа.

Шул ук вакытта Наил Яһудин әле Казандагы финанс-экономика институтында укып, икенче югары белем – экономист таныклыгы ала. Кандидатлык, аннан соң докторантураны бетереп, Мәскәүдә Губкин исемендәге нефть һәм газ дәүләт институтында техник фәннәре докторы диссертациясен яклый.

Башта – КАМАЗдагы төзелеш һәм механизация идарәсенең баш инженеры, аннан соң генераль директоры була.

Ул Чернобыльда, Спитакта да төзү эшләре алып бара. Әле хәзерге вакытта, яңа шартларда да, галим буларак, ул яңа эш алымнарын производствода куллануга кертә. Мәсәлән, нефть калдыкларын, шламны ком һәм балчык белән катыштырып, грунтобетон җитештереп, аны юлга җәюне гамәлгә ашыра.

Самардагы архитектура һәм төзелеш академиясендә дә ул бу юнәлештәге фәнни эшләрне уңышлы алып бара. Ул булдырган арзан, ныклы материалларны хәтта аэродромнар төзегәндә дә кулланалар.

"Без үзебез сайлаган юлдан тукталмыйча, гел алга барып, яңаданяңа уңышлар яуларга омтылып яшибез. Шуңа безне әтиебез өйрәтте!"

эшләгәч, аңа Нурлат шәһәрендә елына 100 мең тонна нефть калдыкларын эшкәртеп, төзелеш материаллары эшләп чыгару заводы төзү бурычы йөклиләр.

Ул заводны төзеп, аны яхшылап эшкә җибәргәч, Шамил Яһудинны "Нурлатнефть"нең НГДУ идарәсенә капиталь ремонт ясау цехының начальнигы итеп билгелиләр. Монда аңа Нурлат шәһәрендә дә киң җәелгән төзелеш эшләре алып барырга туры килә.

Тора-бара ул ОАО "Татнефтепром "Зюзеевнефть" идарәсенең генераль директоры итеп билгеләнә. Шамил Яһудин производство эшчәнлеге белән генә чикләнми. Аның тырышлыгы белән "Ягуар" исемле киң профильле спорт клубы оештырыла, һәм ул аның президенты итеп сайлана. Монда автоспорт, дзюдо, самбо, татар көрәше һәм ат спорты киң җәелеш ала. Биредә көрәш буенча дөнья чемпионнары да тәрбияләнә. Ат чабышларында, авомобиль ярышларында һәм башка спорт төрләре буенча күпләр ил күләмендә югары уңышларга ирешәләр.

Яһудин Шамил – техник фәннәре докторы, фән һәм техника өлкәсендәге уңышлары өчен Татарстан Республикасы премиясе лауреаты, Татарстан Дәүләт Советының 2, 3, 5 һәм 2019 елда алтынчы чакырылышы депутаты. Ул – "Россия Федерациясе газ һәм нефть промышленностеның Атказанган хезмәткәре", "Россия Федерациясенең Атказанган төзүчесе", "ОАО "Татнефть" берләшмәсенең Хөрмәтле хезмәткәре", "Россия Федерациясе ягулык һәм энергетика комплексының Хөрмәтле хезмәткәре", "Физкультура өлкәсендә Татарстан Республикасының Атказанган хезмәткәре" дигән мактаулы исемнәргә лаек була.

Вил Яһудин - дүртенче уллары. Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, Яр Чаллы шәһәрендә эшли, шул ук вакытта Әлмәт газ һәм нефть институтын тәмамлый, Яр Чаллыдагы елга порты генераль директорының урынбасары, аннан соң капиталь төзелешне механизацияләү идарәсе начальнигы урынбасары булып эшли.

Рамил Яһудин – иң кече уллары. Ул Казан Дәүләт медицина институтын тәмамлаган. Югары категорияле табиб-травмотолог. Медицина фәннәре докторы. Казан Дәүләт университеты доценты. Татарстан





Татарстан Республикасы
авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

Рәхмәт хаты

Мөхтәрәм Гәбделхәй Әбҗәлетдин улы!

Сезне 90 яшьлек юбилей туган көнегез белән ихлас күңелемнән котлыйм!

Тормышыгыздагы истәлекле вакыйга уңаеннан, Республикабыз авыл хуҗалыгын үстерүгә багышланган фидакарь хезмәтегезне югары бәяләп, олы рәхмәтемне җиткерәм.

Хезмәт һәм тормыш юлыгыз һәркемгә үрнәк булырлык. Күп еллар Аксубай районында «Дружба» хуҗалыгы җитәкчесе гамәлендә авыл халкы мәнфәгатьләренә битараф булмыйча нәтиҗәле хезмәт күрсәттегез, коллегаларыгыз арасында күренекле шәхес булып таныldыгыз. Шунысы куанычлы, Сез бүген дә авыл тормышы белән даими кызыксынып торасыз.

Гомер бәйрәмегез котлы булсын! Алдагы көннәрегездә Сезгә һәм якыннарыгызга исәнлек-саулык, күңел тынычлыгы, бәхетле тормыш телим. Фидакарь хезмәтегезнең нәтиҗәләре һәрчак шатлык китерсен!

Зур ихтирам белән,
Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары -
авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре, Игенчеләр сарае
август ае, 2017 ел

да әйтелгән кебек.

Алар – илебез кичергән иң авыр заманнарда туып-үскән гади авыл кешеләре. Юклык, бар нәрсәгә мохтаҗлык заманында тормышны җайга салу юлында алар ил файдасына бар куәткә тырышканда әле үз балаларын сокланырлык шәхесләр итеп тәрбияләргә дә вакыт һәм ихтыяр көче тапканнар.

“Бөтен бөеклек гадилеккә бәйләнгән!” (Всё гениальное – просто!) дигән серле әйтем бар.

Сәрвәрия апа гадилеге, йомшак күңеллелеге, төпле акыллы булуы белән меңнәрчә укучылары күңелендә тирән эз һәм якты истәлекләр калдырырлык олы ихтирам яулаган.

Бер укучысының рәхмәт хатында-

Республикасаның Атказанган табибы. Дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән.

Студент вакытында ук Казанда район поликлиникаларында травмотология бүлегендә эшли, тәҗрибә туплый. Ординатураны бетергәч, травмотология һәм ортопедия институтында табиб–травмотолог, бүлек мөдире, директор урынбасары булып эшли, анан соң Республика клиника хастаханәсенең баш табибы урынбасары итеп билгеләнгән.

Шул ук вакытта ул – экономика фәннәре канидаты һәм Санкт-Петербургтагы Мечников исемендәге медицина университетында медицина фәннәре докторы диссертациясен уңышлы яклый.

Кызлары Суфия – инженер-программист, гомерен КАМАЗга багышлаган, 36 ел эшләп, пенсиягә чыга. Хезмәт ветераны.

Кызлары Әлфия – Казан Дәүләт университетының “Вычислительная математика и кибернетика” бүлеген тәмамлый, программист. Тормыш иптәше Рөстәм - экономика фәннәре докторы, Прагада эшлиләр.

Йомгаклап, шуны әйтәсе килә – Габделхәй абзый һәм Сәрвәрия апа корган гаилә тарихында һәм алар үткән тормыш юлында гыйбрәтле һәм сокланырлык нәрсәләр күп.

Мәсәлән, алар үстергән балалар арасындагы ныклы туганлык җепләре.

Һәр елда энеләренең туган көнендә бергә җыелу алар өчен матур бер гадәткә әверелгән. Дәвамчылары белән бергә җыелганда аларның саны хәзер утыз алтыга җитә инде!

Әниләргә карата күп җырлар, төрле әдәби әсәрләр язылган, фильмнар төшерелгән. Аналарны зурлау – ул барлык халыкларда да борынгыдан яшәп килә торган изге гадәт.

Яһудиннар озак еллар яшәгән Аксубай районында чыгып килгән “Якташлар авазы” (Вестник землячества) газетасында:

“Ата кеше йөз мөгаллимнән, ана кеше – йөз атадан өстен!” – дигән атама астында кызыклы язма басылган. Бу гыйбрәтле сүзләр безнең эрага кадәр бер мең ел элек борынгы һинд халкының “Ману Кануннары” исемле законнар җыентыгында язылган булса да, алар нәкъ менә Сәрвәрия апа һәм Габделхәй абзый Яһудиннар турын-



гы юлларда да Сәрвәрия апаның гади бөеклеге ачык күренә. Ул хатта мондый сүзләр язылган:

"...Беренче сыйныфка укырга кергәндә, мин үземне башка дөньяга эләккәндәй хис иттем.

Стенадагы рәсемнәр, парталар, йөзеннән нур бөркелеп торучы укытучым – барысы да күңелгә әйтеп бетергесез рәхәтлек бирәләр иде.

Башта безгә ул "Әлифба" укытачагын, аннан соң татар теле дәресләрен алып барачагын әйтте. Аннан соң сүзне "Әлифба"дан түгел, әкиятләрдән башлады һәм аларны шулкадәр мавыктыргыч, ышанырлык итеп сөйләде.

Боларны без тын алырга да кыймый тыңладык.

Ул әкиятләрдә авыл кешеләре, безнең авыл кырыенда урнашкан тау һәм урман да катнашканга, андагы аюлар, бүреләр, шүрәле һәм су анасы, убырлы карчык, серле йомгак – әйтерсең боларның барысы да кайчандыр биредә торганнар да, тик хәзер картаеп, үлеп кенә беткәннәр кебек тоела иде.

Әкиятләрне генә түгел, дәресләрне дә кызыклы итеп алып бара иде ул.

Сәрвәрия апаның бай тарихлы, гади булмаган гомер кичерүе турында белгәч, миндә аңа карата әле тагын да көчлерәк кызыксыну һәм соклану хисләре туды.

Сәрвәрия апаның шәхси үрнәгендә мин үзем дә укытучы һөнәрен сайладым. Аның биргән тәрбиясе, белемгә карата тудырган мәхәббәте күпләргә тормышта үз юлын табарга ярдәм итте.

Рәхмәт Сезгә, яраткан укытучыбыз!

Хөрмәт белән, утыз дүрт ел буена укытучы хезмәтен башкарган Әхмәтвәлиев Таһир Зиннәт улы. Яңа Үзи авылы", – диелгән ул хатта.

Сәрвәрия апада булган бай кешелек сыйфатлары, аның төпле акыл иясе икәнлеге күп нәрсәдән күренә. Мәсәлән, "Пар канатлар" дип аталган Казан радиосы тапшыруында аның:

"Балаларыбыз тормыш барышындагы мәхәббәт дулкынында безнең пар канатлар астында тәрбияләнделәр.

Минем фикеремчә, иң ышанычлы тәрбия чаралары хезмәткә мәхәббәт һәм белем алуга омтылыш тудыруга бәйләнгән.

Хезмәт сөйгән, белемне хөрмәт иткән кеше тормышта югалмый, һичшиксез, анда үз юлын таба һәм лаеклы гомер кичерә.

Аллаһыга шөкер, балаларыбыз кечкенәдән эшкә өйрәнеп, олылары – кечене, кечеләр олыларны хөрмәт итәргә, кешелекле булырга өйрәнеп үстеләр.

Без алар белән, алар безнең белән горурланып яшибез!" – дип куанып сөйли ул.

Габделхәй абзыйның узган тормыш юлын күзаллаганда да, кайсы гына җирдә, нинди генә авыр эшләрне җитәкләмәсен – ул һәр коллективны алдынгылар сафына бастыруга бар көчен куйган. Шуңа да бар җирдә дә аны тик олы хөрмәт һәм рәхмәтлек хисләре белән телгә алалар.

Ул еш кына: "Ирне ир иткән дә, хур иткән дә – хатын-кыз. Аллаһыга шөкер, минем тормышта ирешкән уңышларым да, балаларыбызның югары дәрәҗәләргә ирешүе дә – барысы да хатыныма бәйләнгән, без барыбыз да аңа бурычлыбыз!" – дип горурланып сөйли.

Хәзер инде алар икесе дә бакыйлыкка күчтеләр. Тик шулай да, алар бу дөньяда мәңге үлмәс һәм даны сүнмәс изге эшләр башкарып, якты истәлекләр калдырдылар.

Теләнгән изге теләкләр, матур истәлекләр һәм күпләрнең рәхмәтлек хисләре аларга дога булып барырлар һәм үзләренең рухларын шатландырып торырлар, дип ышанабыз.

Аллаһы Тәгаләдән Габделхәй абзый һәм Сәрвәрия апа Яһудиннарның урыннарын оҗмах түрендә насыйп итүен сорыйбыз.

Алар – үз гомерләренә моңа лаек булуларын исбатлап яшәүче изге кешеләр бит!






*Бюст Ш.Г. Галеева в Альметьевске*



*Бюст А.Ш. Губайдуллина в Альметьевске*




*Бюст Р.С. Саттарова в Альметьевске*

# БЮСТЫ САМАРЦЕВ В ТАТАРСТАНСКОМ НЕФТЕГРАДЕ

***На Аллее Героев Труда альметьевского парка имени 60-летия нефти Татарстана установлены бюсты 25 Героев Социалистического Труда и полных кавалеров ордена Трудовой Славы. Интересно то, что четыре памятника поставлены уроженцам Самарской губернии. Статья об одном из них – обладателе золотой медали «Серп и Молот» З.Г. Шарифуллине – была опубликована в 31-м номере журнала. Теперь расскажем об остальных Героях Социалистического Труда – наших земляках: Р.С. Саттарове, А.Ш. Губайдуллине и Ш.Г. Галееве.***

**Рашид ШАКИРОВ**

Их биографии весьма похожи: родились во втором десятилетии XX века в Бугульминском уезде Самарской губернии (но в разных населенных пунктах). Получив достаточный минимум знаний, работали на разных предприятиях вдали от ТАССР, прошли солдатами через Великую Отечественную войну, снова трудились, пропуская через себя особенности далей и весей Советского Союза. Но татарстанская нефть «позвала» их на малую родину, и здесь они показали себя в полном блеске, удостоившись высочайших государственных наград.



Начнем изложение с самого старшего из них – **Рашита Саттаровича Саттарова,** родившегося 12 октября 1912 года в с. Маметьево (ныне оно находится в Альметьевском районе Татарстана). Было тогда в селе около трехсот дворов и более 1460 жителей. Где начал Рашит дорогу в мир знаний – неизвестно, хотя в начале века в Маметьево имелись два мектеба, но их, скорее всего, закрыли в годы советской власти. А начальная школа начала действовать только в 1928 году и для 16-летнего юноши уже не подходила.

Годом позже, судя по информации Альметьевской энциклопедии, он уехал работать в Среднюю Азию, а в 1932–1933 годах возводил различные объекты в Ленинграде, став продолжателем семейной династии строителей. Затем были три года срочной службы в армии, причем навыки строителя шлифовались и здесь. После демобилизации Рашит вернулся в Бугульминский район и, окончив курсы трактористов, водил «железного коня» по полям мест-

ных колхозов, в частности, хозяйства «Гремячка» Спасского сельского совета.

В августе 1941 года он стал участником Великой Отечественной войны, Известно, что красноармеец Саттаров участвовал в боях за Ленинград, имел боевые награды (медали «За оборону Ленинграда», «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.») и вернулся к гражданской жизни на следующий год после победного мая.

На сей раз местом приложения его рук и знаний стала железнодорожная станция Чу Джамбулской области Казахской ССР. При станции существовал поселок городского типа Чу (ныне – город Шу), известный прежде всего благодаря расположенной рядом Чуйской долине.

Тем временем на малой родине нашего героя после открытия летом 1948 года богатейшего Ромашкинского месторождения девонской нефти, вошедшего в первую десятку супергигантских залежей мира, начались заметные перемены в социально-экономической жизни территории. Освоение нефтяного месторождения шло полным ходом. Разрабатывать его ехали специалисты и энтузиасты со всей страны, которым нужно было где-то жить. Построенные наспех бараки и щитовые дома, а также поставленные палатки уже не спасали положения. И в 1951 году Саттаров стал каменщиком на площадках села Альметьево.

А через два года он на последующие 20 лет возглавил бригаду каменщиков в строительно-монтажном управлении № 42 строительного треста № 8, входившего то в «Альметьевнефтьстрой», то в «Татнефтестрой». Именно его бригада первой начала строить капитальные двух- и трехэтажные дома в г. Альметьевске, прославившись вскоре своими делами на весь набирающий темпы молодой город.

Но сдавался новый жилой фонд медленно из-за расшивки швов кирпичной кладки. Эту технологическую процедуру на тот момент производили только летом. У Рашита Саттаровича родилась идея ведения расшивки одновременно с кирпичными работами. Своими мыслями бригадир поделился с главным инженером управления М.С. Галиевым. Руководство поддержало Саттарова, и дело пошло быстрее, а впоследствии этот метод практически вдвое сократил трудозатраты и сроки строительства. В дальнейшем он дал хороший эффект в экономии и средств, и времени.

На счету бригады Саттарова десятки возведенных многоэтажных домов, типовые здания кинотеатра «Татарстан» и универмага, школ и детских садов. То есть она внесла солидную лепту в развитие инфра-



*Встреча Р.С. Саттарова с пионерами*



*Р.С. Саттаров на склоне лет*



*Р.С. Саттаров на работе*



*Альметьевск, конец 50-х годов*




*В красный день календаря.
Р.С. Саттаров – в центре*



*Улица Саттарова в Альметьевске*

структуры растущего Нефтеграда, в котором только за 1950–1957 годы были построены и сданы в эксплуатацию 201 тысяча кв. метров жилья, восемь школ, больничный городок, кинотеатр и три клуба.

В 1958 году его бригада первой перешла на трехсменную круглосуточную работу, внедрила хозрасчет. Саттаровцы овладели смежными профессиями, что сократило внутрисменные простои. 48-квартирный дом они возводили за 28–30 рабочих дней вместо обычных трех месяцев. Все это позволяло сберегать сотни тысяч рублей и высвобождать на другие участки до 27 каменщиков.

Понятно, что команда Рашита эфенди неоднократно занимала призовые места в соцсоревновании. А наш герой, который был хорош не только как организатор производства, но и в качестве наставника молодежи, воспитал целую плеяду специалистов. В том же 1958 году Указом Президиума Верховного Совета СССР за достижение высоких результатов в строительстве ему присвоили звание Героя Социалистического Труда с вручением ордена Ленина и золотой медали «Серп и Молот».

Последующие годы принесли славной бригаде новые достижения, а ее лидеру – награды Родины. За боевые и трудовые заслуги он был награжден орденами Октябрьской Революции и Отечественной войны II степени, а также юбилейными медалями. Нашли Героя труда и знаки республиканского и городского масштабов. Так, в 1969 году Рашит абый стал почетным гражданином г. Альметьевска, а три года спустя – заслуженным строителем ТАССР.

Обилие наград не испортило его характер и не вознесло в самооценках. Саттаров охотно встречался со школьниками и рабочей молодежью, занимался общественными делами как член обкома профсоюза работников нефтяной и газовой промышленности, член объединенного постройкома строительного треста и депутат городского Совета депутатов трудящихся. Когда Рашиту эфенди в качестве награды за ударный труд предоставили коттедж, он отдал его под детский сад, решив, что его семья проживет и в обычной квартире.

27 ноября 1996 года знатный строитель ушел из жизни и был похоронен в родном Маметьево. Спустя девять лет в честь его назвали новую улицу в микрорайоне Восточный города Альметьевска.



Второй герой статьи – **Ахат Шарифуллович Губайдуллин** – появился на свет на семь лет позже Саттарова, а именно 2 ноября 1919 года в деревне Тимяшево (ныне село находится в Лениногорском района Татарстана). Поскольку деревня уже в начале XX века имела 215 дворов и 1206 человек взрослого населения, то при мечети с 1910 года существовала начальная школа (мектеб), которую в первой половине 30-х годов преобразовали в семилетнюю школу колхозной молодежи. Окончив это учебное заведение, Ахат отправился на Воскресенский химический комбинат Московской области, где работал слесарем с 1938 по 1941 год. Данный комбинат, первый цех которого ввели в действие в 1931 году, перед началом Великой Отечественной войны уже был одним из самых



*Некоторые члены бригады С.Ф. Кузьмина, пробурившей скважину № 3, 1948 год*

крупных предприятий химической промышленности страны.

За два месяца до начала упомянутой войны парень был призван Воскресенским райвоенкоматом на срочную армейскую службу, которая вскоре стала боевыми буднями в действующей армии. Сайт «Память народа» содержит очень скупую информацию о нашем герое. Известно лишь то, что в мае-августе 1942 года он служил в 317-м зенитно-артиллерийском полку (зап) на Южном фронте, а до июня 1943-го – в 374-м зап на Брянском и Юго-Западном фронтах.

С войны старший сержант Губайдуллин, награжденный медалями «За боевые заслуги» и «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.», вернулся в ТАССР. Здесь он в 1946 году устроился на работу в Альметьевскую контору разведочного бурения треста «Татнефтегазразведка» Татарского совнархоза.

Как рассказывали нефтяники тех лет журналисту С. Гарифуллиной в 2000 году, «было очень нелегко. Добирались до буровых на тракторах, работали до изнеможения. Через наши руки проходили сотни тонн раствора, а единственная техника – носилки. Тонкие будки не защищали от мороза и ветра, которые особенно лютуют в открытом поле. Но



*Буровая Ромашкинской скважины № 3, 1948 год*

мы очень любили свое дело. Считали его закалкой мужского характера. Мы не роптали, понимали, что так приходит профессионализм. Ушли из бурения совсем немногие».

Азы мастерства наш фронтовик, ставший буровым, получал на скважине № 3 – первооткрывательнице Ромашкинского месторождения нефти, под началом бурового мастера С.Ф. Кузьмина. Бригаде Сергея Филипповича, составленной в основном из местных кадров, было поручено строительство и бурение






*Памятник скважине № 3 – первой на Ромашкинском месторождении*

этой скважины. К бурению приступили 31 января 1947 года недалеко от Тимяшево, на вершине Чияле тау (Вишневой горы). Спустя шесть месяцев, 26 июля 1948 года, из скважины № 3 ударил мощный фонтан черного золота. Начальные замеры показали 60 тонн нефти в сутки, а затем дебит увеличился до ежесуточных 120 тонн.

Радости буровиков не было предела, а Кузьмин, обнимая своих ребят, находил для каждого добрые слова. «Ты хорошо поработал, Ахат!» – сказал он Губайдуллину. А тот, окончив курсы, в 1950 году сам стал мастером нефтеразведочной бригады, и многие последующие достижения треста «Татнефтегазразведка» были связаны с его именем.

Уже через год коллектив Ахата эфенди добился рекордной в тресте проходки – 3559 м на бригаду в год. Губайдуллинцы одними из первых внедрили турбинный способ в условиях разведочного бурения, промывку забоя водой вместо дорогостоящего глинистого раствора и освоили новые типы долот. За 10 следующих лет они пробурили сорок разведочных скважин, давших нефть, опережая при этом намечен-

ные сроки и уменьшая затраты. Например, в 1958 году Губайдуллин и его команда дали 10 700 метров проходки вместо 7 тысяч по плану и сэкономили полтора миллиона рублей. А с 1954 года экономия достигла 6,8 млн рублей.

За успехи, достигнутые в бурении, и участие в открытии новых месторождений нефти Ахату Шарифулловичу Губайдуллину 19 марта 1959 года было присвоено звание Героя Социалистического Труда. Тогда же его избрали депутатом Верховного Совета РСФСР V созыва.

В 1961–1972 годах Ахат абый самоотверженно работал и в качестве мастера цеха капитального и подземного ремонта скважин НПУ (НГДУ) «Альметьевнефть». К концу периода его деятельности в названной должности эксплуатационный фонд НГДУ составлял 1585 скважин. Работников этого цеха иногда называют хирургами нефтескважин.

Затем он в течение года был старшим мастером Мензелинского управления буровых работ (УБР) объединения «Татнефть». А в 1973 году нашему герою предложили в Альметьевском УБР занять должность начальника буровой скважины № 20000 – первой в ТАССР сверхглубокой скважины. Возглавив ее строительство – глубиной 5099 м со вскрытием кристаллического фундамента на глубину 3200 м, Ахат Шарифуллович еще раз подтвердил уровень своего мастерства специалиста и организатора производства.

– “Нәрсә генә булмасын – барысы да хәерлегә”, дип яшим мин. Һәм бу, дөрестән дә, һәрвакыт шулай булып чыга.

Барысын да Аллаһы Тәгаләгә тапшырырга кирәк. Дөресендә, сиңа ни кирәген, ничек яхшырак булачагын Ул гына белә бит.

**– Тормышта уңышларга ирешер өчен кеше нинди сыйфатларга ия булырга тиеш, дип санийсың?**

– Максатка омтылышлы булырга тиеш. Ният куеп, шуңа бар көченнән омтылырга. Әмма кеше башын таптап түгел, намусыңны саклап калырга кирәк.

**– Алсу, “бәхет” төшенчәсен һәркем үзенчә аңлый. Ә синең өчен бәхет нәрсәдә?**

– Минем өчен бәхет – ул әти-әниең, туганнарың, якыннарыңның исән-сау, янында булуы.

**– Хыялларың да бардыр?**

– Университетны уңышлы тәмамлап, яхшы табиб булып чыгарга, кешеләргә ярдәм итеп, файда китереп яшәргә телим.

**– Ниятләрең тормышка ашсын, Алсу. Максатларыңа ирешеп, зур уңышлар, яңа үрләр яуларга язсын үзеңә!**



*Эх, чибәр дә татар кызлары! Алсу (сулда) сеңелесе Әминә белән*



# ТАЛАНТЛЫ ГҮЗӘЛЛӘР БӘЙГЕСЕ

***30 августта «Татар кызы - 2021» халыкара бәйгесенең ярымфиналы узды, ә финалы бу елның сентябрендә Үзбәкстанда узарга тиеш.***

**Эльмира СӘЙФУЛЛИНА**

Әлеге бәйгегә нигез 2011 елда Чиләбе шәһәрендә салына. Аның авторы һәм илһамчысы – Чиләбе өлкәсе татар конгрессы рәисе **Лена Рәфыйк кызы Колесникова**. Беренче елда анда Чиләбе өлкәсе кызлары гына катнашкан булган. Ә 2012 елда бәйгенең ярымфиналы Казанда уза, проект Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан да хуплана һәм халыкара статуска ия була. Менә инде ун ел буе сайлап алу туры төрле шәһәрләрдә узып, ярымфинал Казанда үткәрелә. Ә менә финал инде алдагы ел бәйгесендә җиңүче кызның туган шәһәрендә оештырыла. Быел аны Татарстан мәдәният министрлыгы ярдәме белән Бөтендөнья татар конгрессы оештыра.

«Татар кызы» конкурсы матурлык һәм талантлар бәйгесе генә түгел, бәлки, илдә татар мәдәниятен үстерү юнәлешендә эшләүче иң уңышлы алымнарның берседер. Бу бәйге татар идеологиясенең, милли сәясәтебезнең бер өлеше дә булып тора. «Татар кызы» конкурсы – яшьләр өчен туган телне, гореф-гадәтләребезне, тарихыбызны һәм мәдәниятебезне өйрәнү һәм камилләштерү этәргече ул.

Быелгы ярымфиналга чыккан 13 кыз Мәскәү, Ленинград һәм Ростов өлкәләрен, Томск, Әстерхан, Мәскәү, Оренбург, Саратов, Пенза, Төмән шәһәрләрен, Татарстан һәм Башкортостан республикаларын тәкъдим итәләр. Ә Самарның данын бәйгедә Айгөл Минастинова яклады һәм финалга чыкты.

Айгөлгә 26 яшь, ул Челно–Вершины районында туган. Самарның дәүләт тимер юллары университетында укып, икътисадчы белгечлеге алганнан соң, «Пикта» сервис оешмасында ярдәм үзәге белгече булып эшли. Вокал, бию белән шөгыльләнә, китаплар укырга ярата. Әтисе – районның баш ветеринария табибы, хәзерге вакытта лаеклы ялда, әнисе балалар бакчасында завхоз булып эшли.

Әби–бабалары тумышлары белән өлкәнең төньяк өлешеннән һәм











Татарстаннан.

– Өйдә әти-әниләр, әби-бабайлар белән татарча гына сөйләшәбез. Балалар бакчасына йөри башлаганда, мин русча бөтенләй аңламый идем, – дип башлады сүзен Самар гүзәле Айгөл. – Кызганычка, балалар бакчасында һәм мәктәптә гел русча гына сөйләшергә туры килде. Моннан тыш, мин 7 ел музыка мәктәбендә укыдым. Анда да гел русча. Шуңа да карамастан, мин - татар халык җырларына, эстрадасына гашыйк кеше. Үзем дә татарча җырларга бик яратам, татарча китаплар укыйм. Күптән түгел генә Шамил Аляутдиновның «Күңел дөньясы» дигән китабын укып чыктым һәм шунда ук аның тормыш иптәше Зилә Аляутдинованың «Гаилә бәхете серләре» китабын укырга алындым.

Җырчылардан Ришат Төхвәтуллин, Элвин Грей, Әнвәр Нургалиев иҗатын яратам. Гүзәл Уразова бик ошый. Үзем дә аның җырларын җырлыйм. Бер ел элек кенә вокал буенча бик шәп педагог белән таныштым, аның дәресләренә теләп йөрим.

**– Милли җыр-моң белән сине кем таныштырды? Гаиләгездә җырчылар булгандыр, мөгаен.**

– Әнием ягыннан бабам оста гармунчы иде. Без бөтен бәйрәмнәрне, туган көннәрне һәрвакыт зур гаиләбез белән җыелышып уздыра идек. Бабай татар көйләрен уйный, ә без рәхәтләнеп халык җырларын җырлыйбыз. Бабамның бакыйлыкка күчүенә инде унбер ел тулды, әмма бу бәхетле мизгелләр минем күңелемдә якты хатирәләр булып мәңге сакла765начак. Туган нигездән аерылып, Самарда яши башлагач, мин татарча сөйләшүне, милли җыр-моңны бик сагындым. Очраклы рәвештә «Идел» ансамбле, аның җитәкчесе Мидхәт абый Әминов турында ишеттем, концертларына йөри башладым. Бераздан үзем дә ансамбльгә кушылып киттем, хәзер сәхнәдә җырлыйм. Шулай ук мин биергә дә бик яратам. Мәктәптә һәм университетта укыганда бию түгәрәгенә йөргән идем. Киләчәктә Латин Америкасы биюләре белән дә шөгыльләнергә уйлыйм, тик әлегә барысына да вакыт җитми, – дип сөйли әңгәмәдәшем.

**– «Татар кызы»на ничек эләктең?**

– Бу уйламаганда килеп чыкты.





Массакүләм чаралар оештыручы Әлфия Сөләйманова студиясенең интернет аккаутында конкурс турында игълан күргәч, бәйге турында мәгълүмат тупладым. Кыш күңелсез узмасын дип, катнашырга, бәхетемне сынап карарга булдым. Өстәвенә, сайлап алу туры Самарның Loft банкет залында югары дәрәҗәдә оештырылган иде. Бәйге шартлары шулкадәр катгый булыр һәм алга таба халыкара дәрәҗәдәге чарада катнашу өчен сайлану мөмкинлеге бирер, дип мин уйламаган да идем.

Бу хакта сайлап алу этабына әзерләнгән вакытта гына белдем.

2020 елда Самарда узган сайлап алу этабында 13 кыз катнашкан иде. Без иҗади һәм интеллектуаль биремнәр үтәдек. Кызганычка, пандемия аркасында финал булмый калды. Ярымфиналга жюри әгъзаларының гомуми карары буенча гына сайладылар.

**– Ярымфиналга ничек әзерләндең? Нык дулкынландыңмы?**

– Ярымфиналга көн саен әзерләндем. Татар халкы тарихын өйрәндем, иҗади номерымны шомарттым. Аллаһыга шөкер, бу эштә миңа Әлфия Сөләйманова, Лилия Мөхәррәмованың «Никах центр»ы, «Яктылык» мәктәбенең хореографы Алия Сурина нык ярдәм иттеләр. Конкурс өчен видеовизитка әзерләгәндә миңа «Дуслык» оешмасының талантлы операторы Азат Әмиров зур ярдәм күрсәтте. Аларның барысына да чиксез рәхмәтләремне җиткерәсем килә.

Дулкынлану бераз булды инде. Әмма үземне кулда тотарга тырыштым, чөнки дулкынлану уңышка ирешүдә ярдәмче түгел.

**– Чит илләрдән килгән катнашучылар белән аралашуы авыр булдымы?**

– Бәйгедә Бөек Британиядән, Германиядән, Төркиядән, Кыргызстаннан, Үзбәкстаннан һәм Казахстаннан килгән катнашучылар бар иде. Алар барысы да татар телен яхшы аңлыйлар, әмма сөйләшә белүчеләре аз. Үзара без татар телендә аралашырга тырыштык, тел байлыгын арттырырга, сөйләм осталыгын үстерергә омтылдык.

**– Катнашучылар өчен нинди сынаулар әзерләнгән иде?**

**–** Без дүрт төрле сынау уздык. Беренче көнне интеллектуаль этап булды, ул Милли китапханәдә узды. Башта безнең өчен аның буенча экскурсия оештырылды. Китапханәнең барлыкка килү тарихы һәм эш схемасы турында сөйләделәр. Анда искиткеч матур һәм уңайлы. Казанда яшәсәм, һичшиксез, мин анда бик күп вакыт уздырыр идем. Экскурсиядән соң конкурс башланды, ул ике этапта узды. Башта без шоба буенча эләккән темага үз фикеребезне сөйләргә тиеш идек, ә икенче этапта 10 сораудан торган тест уздык. Биредә татарлар тарихы,



бөек татар хатын-кызлары турында, татар язучылары, композиторлары, шагыйрьләре, татар халкының гореф-гадәтләре, милли хатын-кызлар бизәнү әйберләре һәм киемсалымнары турында белемнәр кирәк булды.

Икенче көнне без Салих Сәйдәш исемендәге мәдәният үзәгендә җыелдык. Һәр катнашучы үз талантларын күрсәтү өчен номер әзерләп килгән иде. Үзләрен кыскача тәкъдир иткәннән соң, кызлар жюри әгъзаларына үзләренең иҗади номерларын күрсәттеләр. Жюри составында Татарстан Республикасының атказанган артистлары, Лена Рәфыйковна Колесникова, «Татар кызы» халыкара конкурсы президенты Гүзәлия Гыйниятуллина бар иде.

Өченче көнне без барыбыз бергә «Туган авылым» ресторанында токмач әзерләдек. Жюри камыр белән эш итү, токмач кисү осталыгын бәяләде. Бу көнне кызларның уңганлыгын «Ак калфак» татар хатын-кызлары республика иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова бәяләде. Көннең икенче яртысында мастер-класс форматында кул эшләре этабы булды. Без тамбур җөе белән чигү чиктек. Мастер-классны «Чәкчәк» музеена нигез салучы Раушания Полосина үткәрде. Конкурс тәмамланганнан соң барыбызга да чигү өчен җыелмалар бүләк иттеләр.

**– Айгөл, бу бәйге синең күңелеңдә нинди кичерешләр, хистойгылар калдырды?**

– Бу 6 көнгә катнашучылар өчен гаять бай программа әзерләнгән иде. Без Болгар шәһәрендә, «Чәкчәк» музеенда, Милли китапханәдә, Галиәсгар Камал исемендәге театрда экскурсиядә, «Әйдә шаяРТ» КВН төбәкара татар лигасы финалында, «Печән базары» фестивалендә булдык. Анда мин татар киемнәре дизайнерлары белән очраштым. Аларның эшчәнлеген мин элек социаль челтәрләр аша гына күзәтеп бара идем. Финалга чыгучылар өчен Кама Тамагында махсус фотосессия оештырылды. Андагы искиткеч табигатьнең гүзәллеге мине таң калдырды. Мин кызыклы һәм талантлы кешеләр белән таныштым. Кызганычка, чикләнгән вакыт аркасында барлык катнашучылар белән дә аралашырга өлгермәдем.

менә Төркиядән килгән Адель, Германиядән килгән Назлыгөл, Казаннан Айгөл һәм Санкт-Петербург кызы Азалия белән дуслаштык. Без бергә «Hayal» кунакханәсенең иң матур бер номерында яшәдек, ә төшке һәм кичке ашны «Әкият» курчак театрында урнашкан «ХӨРРИЯТ» кафесында ашадык. Кыскасы, барысы да бик югары дәрәҗәдә оештырылган иде. Бәйге азагында безгә истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

Бу бәйге минем күңелемдә онытылмаслык тәэсирләр калдырды. Бу бер атнада мин тулысынча татар мәдәниятендә «йөздем». Минем өчен бу аеруча кыйммәтле, чөнки Самарда туган телне миңа гаиләдә генә ишетергә туры килә. Мин башка илдә булып кайттым сыман. Шундый татар мәдәниятен саклап калу юнәлешендә эшләүче проектларны оештыручыларга олы рәхмәтемне җиткерәм. Мине Россиянең төрле төбәкләрендә безнең киләчәгебезгә битараф булмаган уяңлы яшьләр яшәве бик куандыра. Безнең көчкуәт – бердәмлектә! – ди Самар гүзәле Айгөл Минастинова.

Айгөлгә финалда да уңышлар телибез.







# РАСТИТЕЛЬНЫЙ ОБРАЗ В ТРАДИЦИОННОЙ КУЛЬТУРЕ

***Растения играют важную роль в традиционных обрядах и фольклоре самых разных народов. Деревья, кусты, травы – всё окружено вниманием. В данной статье рассказывается о некоторых башкирских и татарских традициях, связанных с растительностью.***

**Михаил КРЖИЖЕВСКИЙ**

Вот и закончилось жаркое лето – время, когда кругом царила пышная зелень разных оттенков от изумрудного до малахитового. Теперь к зеленому буйству все больше примешиваются другие цвета – золотистый, багряный, рыжий… Кажется, что деревья надели разноцветные костюмы или, по меткому выражению любознательного ребенка, сделали себе яркие прически.

О мировом древе в мифологии написано немало. О культе деревьев писали разные этнографы, в том числе Д. Фрэзер – в его многочисленных примерах есть и упоминание о культовых рощах финно-угорских народов Поволжья. Обратимся к их соседям – башкирам и татарам.

При появлении первой весенней растительности башкиры проводили коллективный обряд выхода на первую зелень. Собирали щавель, кислицу и другие растения, сопровождая сбор играми, плясками и другими увеселительными мероприятиями.

В дни летнего солнцестояния проводился сбор летних целебных трав. Считалось, что в эти самые длинные дни в году на землю и, следовательно, на растения привлекаются лучшие целительные силы Солнца, воплощенные в лучах.

В обрядовой культуре и фольклоре башкир и татар присутствуют и деревья. Известный исследователь башкир С.И. Руденко писал, что во время путешествия по Уральским горам вблизи башкирских кочевок он встречал деревца, завешанные большим коли-

чеством лоскутков материи. При проводах новобрачной или при приезде в гости к женщине, вышедшей замуж в другой род или другое поселение, женщины и девушки устраивали игры и пляски на ближайшей горной поляне. Перед уходом с горы девушки привязывали к дереву тряпочки, что служило своеобразным гаданием: если лоскуток провисит до будущего лета, то девушка в следующем году непременно выйдет замуж. Женщины также вешали тряпочки, но делали это просто в память о посещении данного места.

Подобные традиции существовали и у других народов, а их реликты мы можем увидеть и сегодня, глядя на старые одинокие деревья, увешанные лоскутками материи.

Автор побывал во всех башкирских и во многих татарских селах нашей области, и везде слышал рассказы о том, что береза – дерево печали, и ее нельзя сажать около дома. Это поверье отражено во многих публикациях. В том числе на страницах нашего журнала. Вместе с тем это дерево часто упоминается для выражения женской красоты: девичий стан сравнивается со стройной березой. Как здесь не упомянуть знаменитый татарский ансамбль «Ак каен» («Белая береза») из села Старое Ермаково Камышлинского района, слава о котором давно распространилась за пределы области?!

У кряшен во время Троицы проводится праздник березы: девушки идут в лес «завивать березу»: дерево это украшается лентами, платками, полотенцами. Люди приносят из леса ветки березы и развешивают их на воротах и в домах. Пожилые люди срубают березку, украшают ее и носят по всему поселению, сопровождая это песнями, а затем опускают дерево в воду.

Стройность и красота девушки также часто сравнивается с яблоней. Символами женской красоты также служат различные цветы, камыш, тальник, спелые ягоды. В башкирских песнях весьма распространен образ черемухи. Непродолжительный период цветения этого дерева сравнивается с быстротечностью времени, а обилие плодов ассоциируется с многочисленными повседневными проблемами.

Сосна – стройное хвойное дерево, в любое время года носящее зеленый камзол и достигающее подчас большой высоты (раньше такие деревья, высокие и прямые, называли корабельными или мачтовыми, потому что они использовались для строительства корабельных мачт). В башкирском фольклоре сосна служит образом силы и могущества, обычно применяется по отношению к мужчинам.

Большое место в фольклоре занимает также курай – растение, из которого изготавливается одноименный музыкальный инструмент, о котором уже писалось в нашем журнале.









# МИН БУЛДЫРАМ!

*(хикәя)*

**Фирдәвес ГАЛИЕВА**

– Ал-ло... Энҗе, сәлам! Ничек анда синең хәлләр?

– Әлфия, бу син?! Сәлам-сәлам! Белсәң, ничек шатмын тавышыңны ишетергә!

– Мин дә сине сагындым. Барып күрергә вакыт юк, үзең килмисең...

– Кая монда кунакка йөрү?! Уку елы башланды гына, бер кочак эш йөкләделәр!

Дустымның тавышында арыганлык, ачыну билгеләре сизелде.

– Кара әле, Энҗе, мәктәп эшен әлегә кадәр яратып сөйли идең, ни булды соң?

– Мәктәп эше бер укытуга гына кайтып калса, ник яратмаска? Бу уку елына, сыйныф җитәкчесе буларак, өстәмә вазифа йөкләделәр.

– Соң нинди вазифа?

– Әй... Шул ата-аналардан акча җыю инде. Әлфия, озакламый дәресем башлана, әйдә кичен шалтыратышыйк?

– Ярый, сау булып тор...

Мин тынып калган кесә телефонымны өстәлдә өелгән китаплар арасына шудердем һәм алдымдагы кәгазь битенә рәт-рәт итеп язган саннарны баганалап кушып, терки башладым. Энҗе минем тынычлыкны алды. Алдагы очрашуларда дустым эшен яратып сөйли иде, балалар укытуга алынуына үкенә үк башламадымы икән? Мин үзем балаларны ничаклы яратсам да, аларны туктаусыз укытып-тәрбияләп торырга түземлек җитмәс иде. Укытучы шыпырт сөйли алмый, ә минем кайчак үз тавышым үз башыма каба, колак шауный башлый. Аллаһы ярдәм бирсен укытучыларга, аларда, мөгаен, үзеннән-үзе бала-чага тавышы кушылып барлыкка килгән гөжнәүне басу теләге туа, ахырда, укытучы кайда булуына карамастан, кычкырып сөйләүче кешегә әверелә. Һөнәри авыруның бер төре, ягъни мәсәлән.

Энҗе белән без бер сыйныфта укымасак та, гел бергә идек. Ул бик тырышып, яхшы билгеләргә укыды, һәммә эшне җиренә җиткереп эшләргә яратты, әйбәт гаиләдә үсте. Әнисе Мәрьям апа кәгазь эшләрен өендә башкара, милициядә эшләүче әтисе Хәбир абый хатынына искерәк компьютер алып, кәгазь эшләрен хәйран җиңеләйтүче махсус програм язып биргән, хатынын шуңарда эшләргә өйрәткән. Энҗе әнисен хәйләкәр, ди. Мәрьям апа бернигә оешмага хисапчы хезмәте күрсәтеп, акчаны, иренә караганда, ике-өч тапкыр күбрәк ала икән, әмма Хәбир абыйга, дәрәҗәсен төшермәс өчен, бу турыда ләм-мим. Өс киеме яисә аяк киеме алгач та, Мәрьям апа аның бәясен бик аз итеп күрсәтә икән, янәсе, акчаны бик саклап тотуны хуплый (ә кайсы ир акча туздыручы хатынны сөя?)

Кыскасы, Энҗе янына килгән мәлләрдә аларның гаиләсендә (аның әле үсеп килүче энесе дә бар иде) һәрвакыт диярлек бер-беренә җылылык, кайгырту сизелде. Мин аларга килгәч, рәхәтләнеп ял итәм: Мәрьям апа, гадәттә, берәр тәмле нәрсә пешереп, безне хуш исле чәй белән сыйлый. Хәбир абый өйдә булса, аларның үзара бер-берсе белән шаяртып сөйләшүләре бу өйдә бәхетле кешеләр яшәгәнен сиздерә иде.

Без Энҗе белән аның бүлмәсендә дәрес әзерлибез, туйсак, музыка тыңлыйбыз яисә егетләрне сөйлибез. Мәктәпнең югары сыйныфларында укучылар төркемнәргә оеша башлый: безнең дә аралашу өчен үз иптәшләребез бар. Алда газиз мәктәбебез, сөекле укытучыларыбыз белән хушлашу торганын, һәрберебезнең үз сукмагы салынасын чамаласак та, күңел моңа ышанмый: ваемсыз яшьлекнең һәрвакыт дәвамы булыр, безнең дуслык та

мәңгелек булып калыр төсле...

Арада егетләрнең берсе - Әнвәр күптәннән Энҗегә гашыйк. Ул аны яшерми дә, дустыма коңгырт күзләре белән сокланып-гаҗәпләнеп карап торганын әллә ничә кат күргәнем бар. Әмма Энҗе аның күз карашын сизмәмешкә салыша, егетнең хисләренә каршы битарафлыгын яшерми. Безнең Энҗе Барби курчагы сыман: аңарда озын нәзек буй, ап-ак чибәр йөз, кыска итеп кистергән бөдрә чәч, кабарынкы иреннәр, ел-майганда битендә чокыр... Болар бары бергә дустымны бик тә мөлаем итә. Әнвәр тәбәнәк буйлы, коеп куйган артист Леонтьев. Ул бездән ике сыйныф алдан укыды, мәктәпне тәмамлауга, хәрби уку йортын сайлап, шунда укырга китте.

Энҗе, урта мәктәпне тәмамлагач, артык зур көч түкми генә, Бауман институтына җитештерүне автоматлаштыру белгечлегенә укырга керде, анда бер ел укыгач, ошатмыйча, Плеханов институтына икътисад белгечлегенә, яңабаштан имтиханнар тапшырып, күчте. Ләкин, аны тәмамлап, Энҗе бер ай булса да, үз белгечлеге буенча эшләде микән?

Көзгә ул педуниверситетка читтән торып укучы иде инде, бер үк вакытта үзе яшәгән райондагы бер мәктәпкә инглиз теленнән укытучы булып урнашты. Инглиз телен Энҗе "су" урынына эчә иде, мәктәптә укыганда ук бу телдә китаплар укыштырганын беләм. Әнисе Мәрьям апа да үз заманында инглиз телен яхшы үзләштергән: кайчакларда ул кызы белән инглиз теленә күчә иде.

Безнең заманда югары уку йортлары, яңгырдан соң чыккан гөмбәләр кебек, төрлесеннән һәм күпләп ачыла башлады, ачылган беренә яктан укытучылар чакыртып, кул астында ни бар – шуны укытырга керештеләр.

Мин үз өемнән ерак булмаган бер институтка читтән торып укырга кердем, белгечлек шул ук икътисад өлкәсеннән иде. Төп белгечлектән тыш, әллә ниткән фәннәр керә башлады: мөмкинлек теориясе, җисемнәр каршылыгы... Миңа, булачак хисапчыга, бу фәннәрне өйрәнү ник кирәк булгандыр – һич аңламадым. Әмма укырга кирәк, белгечлек алмый ярамый, гәрчә мин әлеге эшемне дә яратам: хатын-кызның йөзен матурлаучы, сәламәт рухлы яшәү күрсәткече булырлык кыйммәтле хушбуйлар, ислемайлар, тырнак буягычлар, тагын әллә ниләр сатам.

Безнең илнең базар капкасын төбенә кадәр киң итеп ачтылар: чит илләрдән ниләр генә сатуга килми, матурлык хакына адәм баласы нинди генә ысуллар уйлап тапмый?! Каш ясарга кирәкме, җыерчыкларны бетерергәме - барысы да безнең кибеттә бар! Гомер буе аяк өсте басып эшләп булмас дип, эштән бушаган көннәрдә үземне мәҗбүр итеп диярлек укуга "ябышам": контроль эшләр язам, китапханәләрдә казынам. Бүген минем "буш" көн: эштән соң укуга барасы юк. Андый көннәрдә эштән кайтып, бераз капкалап алгач, уку буенча өй эшләрен үтәргә тырышам.

Әле дә, икътисад фәне буенча катлаулы мәсьәләне чишәргә азапланып утырганда "кылт" итеп дустымның мәктәп проблемнары искә төште. Тагын нинди акча җыюлар инде анда? Ата-аналардан мәктәп кирәгенә акча җыю без укып йөргән заманнарда да бар иде анысы: сыйныф җитәкчебез җәйге каникулга чыкканда фәлән савыт зәңгәр буяу, фәлән савыт ак буяу, фәлән санда пумала, чиләк, башкасын тактага язып, бәясен исәпләп-чутлап, бала санына бүлеп, шул рәвешле безнең аңыбызга алдагы көннәрдә ничаклы җитди эшләр торганын сеңдереп куя иде. Без дә, өйгә кайткач, укытучының гозерен түкмичәчми эти-әниләргә җиткерә идек, алар әлләни каршылык күрсәтми, мәктәп кирәгенә дип, акчаны чыгарып сала торган иделәр. Акча җыю буенча һичкайчан тавыш-фәлән купканын хәтерләмим. Энҗе дә, мөгаен, сыйныф җитәкчесе буларак, яңа уку елына әзерлеккә акча җыядыр. Мин дустымның хәленә керергә теләп, шалтыратып ачыкларга булдым.

– Алло, алло...

– Әйе, Әлфия, тагын бер кат сәлам!

– Сәлам! Ни дип шалтыратам... Ачыклап сөйлә, нинди хәл ителә алмаучы мәсьәлә килеп чыкты синең?

– Соң, шул акча җыюны әйтәм инде.

– Акча җыюның мәктәп кирәгенә икәнен аңламаучы ата-аналар да бармени?

– И-и-и...күп зарланулар булгач, акча җыюлар тыела бит хәзер.

– Соң, тыйгач, ник җыясың ата-аналардан ул акчаны?

– Ник җыясың... Экскурсия оештырам, Байтамак музеена. Сыйныф җитәкчесе буларак, укучыларны әледән-әле музейларга, күргәзмәләргә алып барырга тиеш мин. Андый чараларны бушка үткәреп булмый. Мәсәлән, музейга бару өчен автобус чакыртырга, аңа алдан акчасын түләргә кирәк. Үз кесәмнән түли алмыйм бит инде...

– Анысы билгеле. Ә ата-аналар ни дип карыша тагын? Нәрсә диләр?

– "Кирәге юк ул экскурсиянең, болай да тормыш кыйммәт, акча җиткерер хәл юк", - диләр. Кайсының акчасы аз, кайсы үзе сарандыр инде. Әйтмәсәң дә, бер автобусына гына



да бала башына дүртәр йөз сум акча түләргә кирәк була бит әле ул. Музейга да акча түләп керергә: кеше башына - 200 сум.

– Алай булгач, җәфаланып йөрмә син алар белән!

– Йөрмәс идем дә бит, балалар киң карашлы булып үссеннәр, дим. Ата-аналарына ышансаң, алар кайчан әле балаларын музейларда йөртер? Бар шундый гаиләләр, гомер буе шушы шәһәрдә яшәп, музейларны бар дип тә белмиләр! Аннан соң, без бит - тәрбияче дә әле, шундыйрак эшләргә хисап бирәбез. Заманадан артта каласы килми: үзем дә әледән-әле музейларда булырга яратам. Ниндидер яңалык аласың, тәэсирләнәсең, теге яисә бу вакыйгага карашың үзгәрә... Укучы балаларда да үткәннәргә кызыксыну тәрбияләргә тырышам.

– Ярый, кайгырма, берәр нәрсә уйлашырбыз. Уйлап бетерсәм, хәбәр итәрмен.

– Әлфия, күңелеңә якын алуыңа рәхмәт, тик барча ният ата-аналар ихтыярына килеп төртелә шул!

– Ярый, аңладым. Хәзергә сау булып тор...

– Хуш...

Мин кич буе үземне Энҗе урынына куеп карадым. Менә утыз-кырык кеше сыешлы автобус мин укыткан мәктәп янына килеп туктый. Автобуска мәктәп ишегеннән нибары биш-алты бала чыгып утыра. Юк... Биш-алты бала өчен генә автобус бирмәсләр. Ә ни өчен биш-алты бала гына килгән? Калганнары кая? “Калганнарының акчасы юк...” Энҗе шулай ди. Кесә телефонына акча бар, музейга барырга акча юк.

Кинәт миңа җиңел булып китте. Әйе-әйе... Мин үземчә ачыш ясадым: әгәр калган ата-аналарны музейга баруның арада бер мөһим эш икәненә ышандырсам?

Ул вакытта алар, мөгаен, икеләнми тиешле акчаны чыгарып салыр... Кинәт уйга килгән ошбу фикердән канатланып, мин озынозакка сузмыйча, бер бит кәгазь алып, ата-аналарга мөрәҗәгать язарга керештем.

Хөрмәтле ата-аналар!

Быелның 1 нче октябрендә укучы балалар өчен тирән эчтәлекле экспонатлары белән тирә-юньгә даны таралган Байтамак музеена экскурсия оештырабыз. Бу сәяхәт, һичшиксез, балаларны туган җиребезнең тарихын ачыкларга, каһарман шәхесләребезне барлап, яшәгән җиребезнең кадерен тагын да тирәнрәк тоемларга өйрәтер. Безнең уртак бурыч, хөрмәтле ата-аналар, сыйныфыбызда укучы балаларга үзара туганнарча мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен мөмкинлекләр тудыру да бит әле. Нәкъ шундый сәяхәттә балалар, бутерброд-кәнфитләрен бүлешеп, ныграк дуслаша, берберсенә кирәк вакытта ярдәмгә килергә өйрәнә. Сезнең дә мәктәп еллары булгандыр, сез дә сыйныфташларыгызны сагынасыздыр. Бары тик үзара дуслык, татулык мөнәсәбәтләре генә, беренче карауга, гади күренгән сыйныфта берберсе өчен өзелеп торган кешеләр тәрбияли.




Менә шундый сәяхәтнең мөһимлеген аңлап, балагызны безнең белән шимбә көнгә билгеләнгән сәяхәткә җибәрергә тәкъдим итәбез.

Автобуска бару-кайту өчен бер укучыга билет бәясе - 400 сум, музейны кереп карау 200 сум тора. Шушы сумманы укучы балагыз аша миңа җибәрсәгез иде.

Ихтирам белән сыйныф җитәкчесе Шәмсуллина Энҗе.

Тагын бер кат язганнарны укып чыгып, мөрәҗәгатьтә иң төп шарт - сәяхәтнең максаты ачыкланугa инангач, мин дустыма шалтыраттым.

– Алло, Энҗе, менә, ата-аналарга “хат” әзерләдем, тыңла!

Мин, кесә телефонын колакка терәп, аерым рухлану белән, бер тында “мөрәҗәгать”не укып чыктым.

– Йә, ни диярсең?

– Шә-ә-п, малай! Җибәр минем электрон әдрискә, бүген үк сыйныф сайтына “элеп куям”!

– Алай да, ничәнче сыйныфта укый синең балалар?

– Дүртенче...

Мин көлеп җибәрүдән чак тыелып калдым. Ни өчендер сәяхәткә җыенган сабыйлар җиденче сыйныфларда укыйлар төсле иде. Бу сабыйлардан артык күпне өметләнеп яздым түгелме соң?

Хәер, укытучы апалары хатны “бик шәп”, ди, ә ул укучыларын миннән яхшырак белә булыр. Ахырда мин, зур бер эш башкаргандай, иҗат җимешемне Энҗегә юлладым.

Иртәгә шимбә диган кичне кабат дустыма шалтыраттым.

– Алло, Энҗе, сәлам! Ничек синең хәлләр? Теге хатның ярдәме тидеме?

– Сәлам-сәлам! Тиде генәме соң?! Синнән хат килүгә, аны сыйныф сайтына урнаштырдым. Икенче көнне иртүк балалар акча китерә башладылар. Ике-өч көн дигәндә, бөтен сыйныф сәяхәткә барырга акча тапшырды!

Иң кызыгы: параллель сыйныфтан да биш-алты бала килеп, “апа, безне дә алыгыз әле, әти-әниләрдән рөхсәт бар”, дип торалар. Ничек каршы килим?

Иртәгә шушы сәяхәткә чыгып китәбез! Сиңа нинди рәхмәтләр дә аз булыр төсле!

– Мин бик шат, Энҗе, синең өчен! Менә хәзер аңладың инде: ниндидер максат куйсаң, иң элек, үзең уңышка ышанырга тиешсең, аннан башкаларны ышандыру кирәк.

“Мин булдырам!” дияргә...



# ӨЛКӘННӘРЕБЕЗ – БЕЗНЕҢ КАДЕРЛЕ, ГАЗИЗ КЕШЕЛӘРЕБЕЗ

***Октябрь башында Өлкәннәр көне уздырыла. Бу көнне без өлкән кешеләрне – әби-бабайларыбызны, туганнарыбызны, күршеләребезне котлыйбыз.***

**Гөлназ ТАИПОВА**

Бүгенге сәхифәбезне без кадерледән кадерле, газиз кешеләрәбез – әби-бабайларыбызга багышлыйбыз. Алар – тормыш сынауларын үткән, дөньяның ачысын-төчесен татыган кешеләр. Нинди генә авырлыклар кичерсәләр дә, ягымлы, сабыр, назлы булып кала белгәннәр. Өлкәннәр белән дөньядагы бар нәрсә турында да сөйләшергә була. Алар тыңлый, аңлый һәм гафу итә белә, безне ялгыш адымнардан кисәтә.

Әйдәгез, без дә булдыра алган кадәр әби-бабайларыбызны, өлкән яшьтәге барлык кешеләрне кадерлик, хөрмәтлик, аларга ярдәм итик, тормышларын җиңеләйтергә булышыйк. Бер җылы сүз дә җитә бит аларның нечкә күңелләренә.

**Габдулла Тукай**

**БАБАЙ**

Бабай бик күп яшь яшәгән, карт ул үзе,
Ләкин һаман сәламәт ул, матур йөзе.
Яңак, маңлай җыйрылмаган, тешләр дә сау,
Яшьләрчә саф, ачык чыга аның сүзе.
Җитеп килә инде аның җитмеш яше,
Җем-җем итә җитен сакал, көмеш чәче.
Бабай, мискин, бу дөньяда күпне күргән,
Үлеп беткән инде аның күп яшьтәше.

**Галимҗан Латыйп**

**МИНЕМ ӘБИЕМ**

Әбием күзлек кия,
Чәчләренә ак кунган.
Бер көн дә соңга калмый,
Иртүк тора йокыдан.
Әбекәй, алтыным,
Минем иң якыным.
Яратам, яратам мин аны!

**Шәүкәт Галиев**

**ДӘҮ ӘНИГӘ КҮЧТӘНӘЧ**

Тутырдык без тартмага
Өрек, йөзем, алманы,
Салдык чәй дә, конфет та –
Буш урыннар калмады.
Әй, сөенер дәү әни,
Килеп төшкәч күчтәнәч.
Кызык булыр ул аңа
Алдан белеп китмәгәч.

**Салават Рәхмәтуллин**

**БАСУДА**

Дәү эти буразна яра,
Әтием ашлык ура.
Әтием урган ашлыкны
Абыем ташып тора.
...Дүртәүләп кайтабыз кичен –
Сузыла күләгәләр.
Арыганнар, ахры... мине
Алмашлап күтәрәләр...

**Шәүкәт Галиев**

**БОРАУ**

Сорамадым соравын,
Алдым бабай боравын.
Нинди файда эшлисе,
Кайда, нәрсә тишәсе?
Борауны борам, борам,
Борам, остара барам!
Боравымны кулдан алып,
Колакны борды бабам...

**Әминә Бикчәнтәева**

**ДӘҮ ӘНИЕМ**

Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел ул,
Ул - минем дәү әнием.

Ак ефәктәй чәчләрен
Ул тарап куя үреп,
Чисталыкка өйрәнәм,
Мин дә аңардан күреп.

Мин бакчага киткәндә
Озатып кала мине.

Кайтканда каршы ала,
Бигерәк тә әйбәт инде.

Кызыклы әкиятләр
Сөйли кичләрен безгә,
«Бәбкәм», – диеп иркәләп
Эндәшә үзебезгә.

Күзлексез күрмәсә дә,
Таяксыз йөрмәсә дә,
Җитмеш яше тулса да,
Бик картайган булса да,

Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөләр үстерә,
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.

Җылы оек-бияләй
Бәйли безгә көз җиткәч.
Мин дә аңа бүләкләр
Алырмын үсеп җиткәч.

Өйдә аны һәммәбез
Яратабыз, сөябез:
– Син, бик кадерлебезгә,
Озак яшә, – диябез.



**Мәҗит Гафури**

## ӘБИ БЕЛӘН ОНЫК

Бер әбинең оныгы булган. Кечкенә кызчык йоклаган да йоклаган. Әбисе бөтен эшне үзе эшләгән: кызчык өчен икмәк пешергән, өй җыештырган, юган, теккән.

Тора-бара әбисе картайган. Ул мич башына менеп яткан. Инде хәзер әби йоклаган да йоклаган. Ул арада оныгы үсеп җиткән. Әбисенә ул икмәк пешергән, өй җыештырган, юган, теккән.

**Абдулла Алиш**

## ӘБИЛӘРДӘ КУНАКТА

Беркөнне әни миңа:

– Кызым, Гөлгенә, ятратканым син генә, кил, әйдә, киен, әйдә, әбиләреңә барабыз, бүләк илтеп кайтабыз, – диде.

Мин бик шатландым. Шатлыгымнан җырлый да башладым.

– Барабыз, барабыз, әбиләргә кунакка!

Әни дә мин, без икәү, киттек әбиләргә, әбиләр бездән еракта торалар. Безнең капканы чыгасың – бер, Маратлар капкасы – ике, Хәлимнәрнеке – өч, Гарифларныкы – дүрт, Асияләрнеке – биш. Ә аннан соң бик күп, бик күп капкалар бар.

Безнең урам белән туп-туры барасың, барасың да сулга борыласың. Аннары тагын барасың-барасың да уңга борыласың. Аннары бер урамга борылып керәсең дә, кырыйдан бер йорт кала, икенчесен дә үтәсең, өченчесенә дә кермисең, дүртенчесен дә узып китәсең, ә бишенче йорт – әбиләрнеке.

Беркөнне мин бик яхшы билгеләп кайттым. Аларның йорты каршында гына трамвай туктый. Бик билгеле урында безнең әбиләр йорты!

Әбиләр тора торган йорт бик зур. Түбәндә бер тәрәзә бар, аның өстендә тагын бер, аның өстендә тагын. Кул бармакларының барысын да берәм-берәм бөгеп бетерәсең: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү... тәрәзәләрнең очына чыга алмассың.

Әни әйтә:

– Әбиләрең бишенче катта торалар, – ди.

Без баскычлар буйлап шул бишенче катка атлыйбыз.

Берне менәбез, икене, өчне менәбез, дүртне, бишне. Бик күп баскычлар менсәк тә, әле без беренче катта гына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар.

Ял итәбез дә тагын менәбез: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү... тагын бик күп баскычлар менәбез. Бу әле бары икенче кат кына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар. Тагын баскычның бер басмасы артта кала, ике басмасы, өч басмасы, дүрт, биш басмасы. Без әле бары өченче катта гына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар.

Без тагын менәбез, тагын менәбез. Беренче катны менгәч, ял итәбез, икенчене, өченчене, дүртенчене менгәч, ял итәбез дә бишенче катка менеп җитәбез. Безнең әбиләр менә шушы бишенче катта торалар.

Анда ишекләр бик күп: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү...

Ә ишек яңагында бер түм-түгәрәк әйбер бар, аның уртасында бер төймә дә бар, әни шул төймәне бармагы белән басарга тотынды. Бер мәртәбә басты, эчтә «чылтыр!» итте.

Икенче мәртәбә басты – тагын «чылтыр!» итте, өченче мәртәбә баскан иде, берәү:

– Кем бар? – дип сорады.

Әни әйтте:

– Кызым Гөлгенә дә мин генә.

Ишек ачылды. Аннан әби килеп чыкты, ул көлә иде. Ул мине күтәреп алды.

– Ай, кызым Гөлгенәм килгән, бик сагындырдың, бер атна бит инде сине күргәнем юк, – диде.

Без өйгә кердек. Мин әнидән әкрен генә сорадым:

– Әни, атна нәрсә соң ул? – дидем.

Әни әйтте:

– Җиде көн, – диде. – Дүрткә берне кушсаң, биш була бит. Бишкә берне кушкач, алты көн була, алты көнгә тагын берне кушсаң, җиде көн була. Менә шул бер атна инде.

Әби безгә чәй эчертте. Безне коймак белән сыйлады. Мин биш коймак ашадым. Әни биштән дә күбрәкне ашады.

Мин бер чынаяк чәй эчтем, әни өчне эчте, ә әби биштән дә күбрәк, җидедән дә күбрәкне эчте.

Без әбигә бүләгебезне бирдек. Алар кып-кызыл алмалар иде. Әби ике кулына икешәр алма токач та, өстәлдә әле тагын биш алма калды. Барысы күпме булгандыр, мин белмәдем. Биштән дә күп, җидедән дә күбрәк.

Аннары без өебезгә кайтып киттек, әби безне озатып калды.



**Хәкимҗан Халиков**

## ВИТАМИНЛЫ АШ

Мәктәптән кайтып керүгә:

– Нәрсә пешердең, дәү әни? Өйгә тәмле ис чыккан, – диде Тәнзилә.

– Витаминлы аш пешердем, кызым. Яз көне витаминнар җитми безгә, – диде дәү әнисе Сәхипкамал әби.

– Витаминны кайдан алдың соң? Даруханәгә бармагансыңдыр ич?

– Бакча рәшәткәсе буенда мине үзе көтеп торган.

– Кызык, мин аны даруханәдә генә була, дип уйлаган идем.

Тәнзилә кулын тиз генә сабынлап юды да өстәл янына килеп утырды. Дәү әнисе тәлинкәгә аш салып бирде. Аңа бер кашык каймак өстәп болгатты да:

– Йә, ашап кара инде, – диде.

Тәнзилә тәлинкәне бик тиз ялт иттерде:

– Рәхмәт, дәү әни, тәмле аш пешергәнсең. Тагын пешер, яме.

– Пешерермен, кызым, пешерермен. Кычыткан җитәрлек, – диде Сәхипкамал әби, кет-кет көлеп.

Тәнзилә шаккаты:

– Кычыткан чага бит ул! Ә мин сизмәдем дә.

– Пешергәч, юашлана ул шулай.

Сәхипкамал әби андый витаминлы ашларны кузгалак, сәрдә, балтырган кебек үләннәрдән дә пешерде. Тузганак яфрагыннан салат та ясаштыргалады. Тәнзилә аларның һәркайсын бик яратып ашады. Тузганак тамырыннан әзерләнгән төнәтмәне дә мактый-мактый эчте. Сөтле кофе, дип уйлады. Сулышы кысыла башласа, дәү әнисе шуны гына эчә.

Менә ямьле җәй дә җитте. Су буйлары, болыннар шау чәчәккә төренде. Дәү әнисе кебек, Тәнзилә дә аларны бик ярата. Шулай беркөнне йөгереп кайтып керде дә:

– Дәү әни, хуш исле ромашка да чәчәк аткан! Инешкә төшә торган сукмак буенда бик күп икән ул, – диде.

– Алайса, аны да җыяр вакыт җиткән, – диде Сәхипкамал әби. – Әйдә, мал-туар таптаганчы җыеп керик, кызым.

Алар бер кулларына - кайчы, икенче кулларына кәрзин күтәреп чыктылар да ромашка чәчәкләрен кисә башладылар. Ул арада Тәнзиләнең иптәш кызлары да килеп җитте. Әй, китте эш, китте кызып, кызларның куллары кулга йокмый. Һәркемнең күбрәк җыясы, күршесеннән уздырасы килә. Тырышлык бушка китәме соң! Төш җиткәндә, барысының да кәрзиннәре хуш исле ромашка чәчәкләре белән тулган иде инде.

Сәхипкамал әби икенче көнне Тәнзиләне елга буена алып төште. Яр буендагы дымлы урыннарны эт тигәнәге үләне каплап алган иде. Чәчәккә бөреләнгән генә вакытлары. Аларның очларын нәкъ шундый чакта җыярга кирәк.

Дымлы урыннарда песи үләне дә шактый күп иде. Әмма Сәхипкамал әби аларга кагылмады.

– Орлыклары өлгереп коелсын әле, – диде. – Тамырларын көз көне казып алырбыз. Йөрәк авыртканда эчә торган валериан тамчыларын шулардан ясыйлар инде.

– Аны ни өчен песи үләне диләр соң?

– Тамырын песиләр ярatkанга.

Эт тигәнәге белән тулган кәрзиннәрен күтәреп кайтырга гына чыкканнар иде, Тәнзилә тышкы күренеше белән курайга охшаган үсемлек күреп алды.

– Дәү әни, әнә балтырган да бар икән монда.

– Без аш пешерә торган балтырган түгел ул, кызым, су балтырганы. Аның агуы шулкадәр зәһәр, хәтта кешене дә үтерә, – диде Сәхипкамал әби. – Исеңдә тот: әнә вак кына ак чәчәкләре бергә җыелып, зонт сыман булып тора. Яфраклары саплы, өч-дүрт өлешкә телгәләнгән. Әгәр аны, уч төбенә салып, бармак белән изсәң, тәмсез ис чыга.

Чүплектә үскән миңгерәткеч белән тилебәрән орлыгын күргәч, оныгын тагын кисәтте Сәхипкамал әби:

– Бу үләннәрнең дә тартмачыктагы орлыклары бик агулы. Мәк дип, аларны ашаган кайбер балаларның үлү очраклары да бар.

Ә менә шунда ук үскән сукыр кычыткан чәчәкләрен күпләп җыйдылар алар. Бу чәчәктән аптекада йөрәк даруы ясыйлар. Сәхипкамал әби исә аннан төнәтмә әзерли.

Тәнзилә дәү әнисе белән урманда да еш була. Алар анда җиләк тә, көрән мәтрүшкә дә җыялар. Аны да кайчы белән генә кисеп алалар. Иң зурларын орлыкка калдыралар.

Шулай бервакыт Тәнзилә, кечкенә генә куак күреп, кинәт туктап калды. Аның кып-кызыл җиләкләре сабак буйлап тезелеп төшкән иде. Берсен алып кабыйм гына дигәндә, бәхетенә, дәү әнисе күреп алды:

– Чү, нишлисең, кызым?! Бүре җиләге бит ул. Аның хәтта кабыгы да агулы.

– Ә монысы нинди җиләк? – диде Тәнзилә.

– Дүрт яфрак уртасыннан үсеп чыккан сабак очында кара җимеше дә бар. Кош күзе сыман ялтырап тора. Шуңа күрә дә карга күзе, дип атала. Ул да бик агулы.

Тау битләрендә үскән сары мәтрүшкәне дә, сап-сары гөлбадран чәчәген дә шактый күп җыйдылар алар. Көчкә күтәреп кайттылар. Һәр үләнне күләгәдә аерым-аерым яхшылап киптерделәр. Сәхипкамал әби аларның һәркайсын кечкенә янчыкка яки кәгазь капчыкка салып куйды. Үзләреннән артканын Тәнзилә даруханәгә илтеп тапшырды.



**Әминә Бикчәнтәева**

## ТӘМЛЕ СҮЗ

Минем әбиемнең һаман әйтә торган сүзе бар. Ул безгә һәрвакыт:

– Балакайларым, тәмле телле, тәмле сүзле булмасагыз, үзегезне беркем дә яратмас, – ди. Тик мин башта бу сүзне бер дә аңлап җиткерми идем. Ничек инде сүз тәмле була ала икән?.. Ул бит конфет та, прәннек тә түгел. Аны ашап карап булмый ич.

Мин үзем белгән сүзләрне әйтеп карыйм: «Әти, әни, күмәч, ипи, бир, кил, кит, матур, кечкенә, зур, акыллы, ал, кызыл, зәңгәр, ат, сыер, кәҗә...» Сүзләр бик күп инде ул. Зур үскән саен, сүзләрне дә күбрәк беләсең. Тик менә әбием әйткән сүз нинди була икән соң?

Менә беркөнне безгә кунак апа килде. Ул миңа бик матур курчак алып килгән. Мин, курчакны алгач: «Рәхмәт, апа», — дидем. Ул миңа: «Дәү үс», — диде. Шул арада минем янга иптәш кызым Рәйсә килеп керде. Минем кулымдагы курчакның матурлыгын күреп, Рәйсәнең исе китте. Чыннан да, курчагым бик матур. Күзләре зәп-зәңгәр, үзләре миңа карап торган шикелле! Чәчләрен, укучы кызлар кебек, артка бәйләп куйган. Зәңгәр ефәк күлмәк кигән!

– Абау, Гөлкәй, курчагың бигрәк матур икән, – ди Рәйсә. Ә мин аңа:

– Матур шул, кунак апа китерде, әйдә, бергә уйныйбыз, – дидем. Шуннан соң без минем уенчыкларым торган почмакка бардык та уйный башладык. Ә бездән ерак түгел диванда әни белән кунак апа сөйләшеп утыралар. Үзләре, сокланып, безнең уйнаганны карыйлар.

– Кызың нинди үскән инде, – ди кунак апа. Әнием дә миңа елмаеп карый.

– Әйе, зур үсте. Бакчада өлкән группага йөри хәзер, – ди. Иптәш кызым Рәйсә минем курчакны алды да кечкенә урындыкка утыртты.

– Кит әле, шулай утырталармыни, юләр. Бир үзем утыртам, – дип, мин курчакны тартып алдым. Кунак апа да, әни дә ялт итеп безгә карадылар. Әйтерсең лә берәү матур чынаякны төшереп ватты. Аларның йөзләре шундый күңелсез булып китте. Кояш батып, болыт каплаган шикелле, йөзләрендәге елмаю бөтенләй юкка чыкты.

– Абау, нинди сөйләшү бу?! Иптәш кызларың белән шулай тупас сөйләшергә ярыймыни? Кит әле, юләр, имеш. Ә син миңа курчак өчен рәхмәт әйткәч, мин сине тәмле телле дип уйлаган идем, – ди кунак апа. – Ә син шундый тәмсез телле дә буласың икән.

Әнием дә минем өчен оялды, ахры. Ул тиз генә минем ике кулымнан тотып алды да:

– Хәзер үк дустыңнан гафу үтен, – диде. Мин иптәш кызымнан:

– Гафу ит, Рәйсә! – дип гафу үтендем. Хәзер инде мин тәмле телнең нәрсә икәнен беләм. Моннан соң беркем белән дә болай тупас сөйләшмәм.

**Резеда Вәлиева**

## ТУГАН КӨНДӘ

Бүген Фәридәнең туган көне. Әнисе, иртүк торып, бик матур торт пешерде. Өстәлгә төрле-төрле тәмле-татлы сый тезде.

Өстендәге күлмәге дә бик матур бүген Фәридәнең. Анысын да әнисе тегеп кидерде аңа. Чәчләренә, күлмәге төсле үк, тасмадан күбәләкләр такты.

Өйләре дә искиткеч матур бүген аларның. Бөтен нәрсә ялт иткән! Бар да чиста, бар да пөхтә, бар да матур, бар да елмаеп-көлеп кенә торгандай күренә.



Фәридә, куана-куана, тирә-якка күз йөртеп чыкты. Күр инде, хәтта өстәлдәге чәчәкләргә кадәр елмая. Әле бүген генә алып кайткан, күрәсең, аларны әнисе!

Бар да шундый матур, шундый күңелле! Тиздән аның дус кызлары да килеп җитәр...

Фәридә әнисе янына аш бүлмәсенә керде.

– Әни, әни, дим, әйдә, әби бүгенгә генә залга, минем кунакларым янына чыкмасын, ә? Югыйсә, бүген анда бөтен нәрсә шундый матур, шундый яңа, ә әби шундый иске, әйем лә, шундый карт... бер дә килешми.

Әнисе башта аңламыйча торды. Аннары, кинәт кенә хәлсезләнеп киткәндәй, кулларын салындырып, урындыкка сеңде. Кулларын тезләренә куйган килеш, байтак вакыт шулай сүзсез утырды ул. Аның йөзе бөтенләй үзгәргән, зур күзләре тирәнәеп, каралып киткәндәй булган иде.

– Менә нәрсә, Фәридә, дусларыңа шалтыратып әйт: бүген туган көнеңне уздырмыйбыз. Менә шулай, уздырмыйбыз... – диде ул.

информационный медиапортал

# Самарские татары
# Самар татарлары

## samtatnews.ru

Самарские татарские новости

**ЖДЕМ ВАШИХ ПРЕДЛОЖЕНИЙ ПО СОЗДАНИЮ САМАРСКОГО ТАТАРСКОГО ИНТЕРНЕТ-ТЕЛЕВИДЕНИЯ.**



## ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР



Телефон для связи 8-917-104-44-45 – **Сайфиев Данияр Урекович**
Адреса электронной почты – **Samartatarlary@bk.ru, ilyas65@mail.ru**



**ПРИОБРЕСТИ НОМЕРА ЖУРНАЛА «САМАР ТАТАРЛАРЫ» МОЖНО ПО СЛЕДУЮЩИМ АДРЕСАМ:**
Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»), пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»), магазин «Булгар» (бывший «Итле-сетле») на территории Соборной мечети Самары.



# ООО «АКТАШ» предлагает услуги по правовой защите граждан и организаций



## ОКАЗЫВАЕМЫЕ УСЛУГИ:

- Юридическая помощь физическим лицам
- Юридическое абонентское обслуживание компаний
- Представительство в арбитражных судах и судах общей юрисдикции
- Услуги в области взыскания задолженности



За дополнительной информацией обращаться по телефону

**8 (927) 797-82-80**

либо по адресу: г. Самара, проспект Кирова, д. 206.